ЯҢАДАН «ТУУ»

Халыкны янә «МММ» системасына җәлеп итәләр

> 5

КАБАК ПАТШАЛЫГЫНДА

Һәвәскәр бакчачы Салихҗан Әхмәтханов, кабак колорадо коңгызын бетерә, ди

> 6

ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА:

«Авырлыкларны кичеп чыгу ошый миңа»

> 12

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 146 (28728) | Җомга | 8 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ӨЛКӘН КЕШЕСЕ – 108 ЯШЬЛЕК ЗӘРИГА ШӘЙДУЛЛИНА:

«ОЗЫН ГОМЕР СЕРЕ – КЕШЕГӘ НАЧАРЛЫК ТЕЛӘМӘҮ»

Зәрига әби Әлмәт районының Түбән Мактама авылында яши. Сентябрь ахырында туган көнен билгеләп үткән әбекәй зарланырга яратмый. Ул әле дә шат күңелле, зирәк акыллы, дөньядагы бар яңалыктан хәбәрдар.

> 17

Ишетми калмагыз

Президентның еллык Юлламасы

Бүген алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының 25 нче утырышы уза. Әлеге чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республика Дәүләт Советына еллык Юллама белән мөрәҗәгать итәчәк.

Республика җитәкчесенең Парламентка еллык Юлламасы Татарстанның икътисад, социаль, мәдәният һәм башка өлкәләренең нәтиҗәле үсеше буенча барлык дәрәҗәдәге дәүләт органнары эшчәнлеге программасын билгели. Утырыш ТНВ, «Болгар» радиосы, Дәүләт Советының рәсми сайтында трансляцияләнәчәк.

Теманың дәвамы 3 нче биттә >

Шәхси клиникаларда да прививка ясыйлар

Коронавируска каршы вакцинаны мәҗбүри медицина иминияте системасында эшләүче шәхси клиникаларда да бушка ясатырга мөмкин. Бу хакта закон 1 октябрьдән гамәлгә керде. Клиникаларга кирәкле дарулар өчен акчаны федераль бюджеттан бүлеп бирәчәкләр. «Шәхси клиникаларга килеп, кешеләр илкүләм профилактик прививкалар календарена кергән авыруларга каршы вакцина ясата алачак. Бу, аерым алганда, грипп, пневмококк һәм кызамык кебек чирләр», – диде Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин. Илкүләм календарьга 12 төр прививка кертелгән.

Казан кырында очрашу

«Ак Барс Арена» стадионында – тарихи очрашу. Футбол буенча Россия җыелма командасы бүген Словакиягә каршы 2022 елгы Дөнья Чемпионатының сайлап алу турниры кысасында чираттагы матчын уздыра. Уен 21.45 сәгатьтә башланачак.

Исегезгә төшерәбез: футбол матчы көнендә башкалада җәмәгать транспорты йөрешенә үзгәрешләр кертелә. «Ак Барс Арена» стадионы янынан узучы трамвай, автобус, троллейбусның эше төнге 1.00 сәгатькә кадәр озайтылачак, өстәмә транспорт җәлеп ителәчәк.

Россия футболчыларының Словакиягә каршы матчын стадионга килеп 13,5 меңнән артык тамашачы карый алачак. Уенга вакцинация яисә коронавирус белән авыру турында белешмә булган очракта гына кертәләр.

Районнарда ни хәлләр?

Биектау

Биектау районы үзәк хастаханәсендә кабат ковид-госпиталь ачылды. Ул 72 урынга исәпләнгән. Госпиталь хезмәткәрләре үз эшләренә бик җентекләп әзерләнгән: дәвалау учреждениесе тиешле медицина җиһазлары, дарулар белән тәэмин ителгән. Барлык амбулатор хезмәт күрсәтә торган медицина бүлекләре элеккечә эшли. Шул исәптән травмпункт та кичке һәм төнге режимда, ял көннәрендә дә эшләвен дәвам итә.
(«Биектау хәбәрләре»)

Зәй

Өлкәннәр декадасы уңаеннан, яшьләр эшләре идарәсе белгечләре әбиләр өчен матур көзге фотосессия оештырган. «Без әби-бабайларыбызны яратабыз, чөнки алар – безнең таянычыбыз. Әмма еш кына алар өйдә, оныклар, гаилә мәшәкатьләре белән мәшгуль, үзләре турында уйларга вакытлары калмый. Без гүзәл әбиләребезне дәшеп, профессиональ фотосессия оештырдык», – диләр идарә белгечләре.
(«Зәй офыклары»)

Кайбыч

Район прокуратурасы хезмәткәрләре бина каршына 50 төп агач утыртты. Россия прокуратурасының 300 еллыгына әзерлек кысасында нигез салынган бу аллеяда чия, кизил, нарат, чыршы һәм башка агачлар үсәчәк. Юбилей 2022 елның 12 гыйнварында билгеләп үтеләчәк.
Прокуратура хезмәткәрләре аллеясы бу өлкәдә төрле авыр елларда эшләүчеләрнең данлы хезмәт батырлыгына дан җырлау максатын да күздә тота.
(«Кайбыч таңнары»)

Апас

Район башлыгы тәкъдиме белән «Иң яхшы мәдәният йорты» бәйгесе игълан ителде. Махсус комиссия авыл җирлегендәге мәдәният йортлары эшчәнлеге белән якыннан танышып йөри. «Клублар гөрләп эшләргә, бу эшчәнлектә җирле халык мәнфәгатьләре дә исәпкә алынырга, алар үзләре дә җәлеп ителергә тиеш», – ди район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Луиза Сафина.
(«Апас-информ»)

Чирмешән

Иске Кади авылындагы Тукай урамында урнашкан төп мәчеттә төзекләндерү эшләре дәвам итә. «Быел төзелеш материаллары нык кыйммәтләнсә дә, бер ниятләгәч, мәчетнең манарасын янартып, түбәсен профнастил белән ябарга уйлыйбыз, – ди Иске Кади авылы мәчете имамы Солтан Мөхетдинов. – 287 мең сумлык калай кайтарттык. Төзелеш материаллары сәдака акчасына, авылдашлар ярдәме белән алына.
(«Безнең Чирмешән»)

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:
«ЯХШЫ ПОЗИЦИЯ – ҮЗМАКСАТ ТҮГЕЛ»

«Татарстан төбәктә инвестицион климатны яхшырту буенча эшне дәвам итәчәк. Билгеле, бу ресурслар, финанс чыгымнары таләп итә – без әзер». Министрлар Кабинетында республиканың икътисади үсешен тәэмин итү өчен эшлекле климатны яхшырту буенча узган утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде.

Утырышны алып барган Премьер-министр Алексей Песошин искәрткәнчә, Татарстан Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингында Россия субъектлары арасында икенче урында тора. 2019 һәм 2020 ел нәтиҗәләре буенча, әлеге рейтингның беренче баскычына Мәскәү урнашкан.

– Үсеш әллә ни зур түгел, ләкин монда башкасы мөһим. Безнең һәрберебез илкүләм проектның эшчәнлегебезне билгеләүдә бары тик инструмент икәнлеген генә аңлый. Төп бурыч – республикада бизнес алып бару өчен даими һәм уңайлы шартлар тудыру, – диде Алексей Песошин.

«Яңа проектларны үстерү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» генераль директоры Светлана Чупшева рейтинг инде 7 ел дәвамында төзелүен һәм Татарстанның лидерлык позицияләрендә торуын билгеләп узды. Моннан тыш, аның сүзләренчә, республика инвестицион климатны яхшырту өчен бик күп гамәли эшләр һәм карарлар биргән. Болар – электр челтәрләренә тоташтыру, кече бизнеска ярдәм итүдә инструментлар һәм башкалар.

Шулай ук Светлана Чупшева Россия Президенты Владимир Путин карары буенча тагын бер рейтингның эшләнүен дә хәбәр итте. Федерация субъектларында яшәү шартлары рейтингы илкүләм рейтингына өстәмә булачак барачак һәм үз эченә медицина, социаль яклау, мәгариф, торак, дәүләт хезмәтләре, сервислар һәм башка күрсәткечләрне алачак.

Утырыш тәмамлангач, Рөстәм Миңнеханов һәм Светлана Чупшева журналистларның сорауларына җавап бирде. Республика җитәкчесе фикеренчә, инвестицион климатны яхшырту буенча эшләр җитәрлек дәрәҗәдә алып барылмый. Эшнең төгәл системасы һәм барлык гамәлләрнең ачык булуы кирәк.

– Без нинди документның һәм нинди карарның тоткарлануын күрергә тиеш. Бюрократлар һәрвакыт тоткарлаячак, – диде ул. – Төгәл система булмый торып, берни дә ачык күренмәячәк.

Шулай ук Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, якын арада районнарның инвестицион климаты торышы буенча да мәгълүматлар билгеле булачак. Моннан тыш, ул әлеге мәсьәләдә иң яхшылардан үрнәк алачакларын әйтте.

– Кайбер позицияләр буенча Мәскәү нык алга китте. Алардан иң яхшы тәҗрибәләрне алачакбыз, – диде ул.

Шулай ук республика җитәкчесе инвестицион климатны яхшырту мәсьәләсендә цифрлы технологияләрне куллануның мөһимлеген билгеләп узды.

– Эш дәвам итә, – диде Рөстәм Миңнеханов, нәтиҗә ясап. – Рейтингта яхшы позиция алу – үзмаксат түгел. Бу беренче чиратта – инвестицияләр килү. Әгәр безгә килмәсәләр, алар Ульян өлкәсенә, Самарага китәчәк. Бизнес ул – күчмә кошлар кебек, кайда яхшы шартлар тудырылган, шунда килә. Шуңа күрә эшләячәкбез һәм тудырылган шартлар уңышлы булыр дип өметләнәбез.

ТӨНЬЯК БАШКАЛАДА – ТАТАРСТАН ТЕХНИКАСЫ

Бу көннәрдә Санкт-Петербургта унынчы тапкыр Петербург халыкара газ форумы уза. Форум эшчәнлегендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Халыкара чарада Татарстан 16 сәнәгать предприятиесен тәкъдим итте. Шулар арасында «Газпром Трансгаз Казан», «Виконт», «Реал», «КамАЗ» кебекләре дә бар. Форумның беренче көннәрендә катнашучылар күргәзмәдә тәкъдим ителгән проектлар белән танышты.

Күргәзмәне «Газпром» җәмгыяте Директорлары советы рәисе Виктор Зубков та карады. Республика Президенты аңа Татарстандагы техника үрнәкләрен күрсәтте. Шуларның берсе – «Раритэк Холдинг» компаниясе җитештергән кысылган табигый газда йөрүче экскаватор. Россиядә бу беренче шундый техника. Моннан тыш Зубков МТЗ-1221 тракторы өчен 6 цилиндрлы двигатель үрнәге белән дә танышты.

Санкт-Петербургтагы форум кысасында Рөстәм Миңнеханов «Чайка» пассажир судносына ачкыч һәм документлар тапшыруда катнашты. Әлеге судно шулай ук кысылган табигый газда эшләячәк.

Татарстан газ-мотор ягулыгы базарын үстерү дәрәҗәсе буенча биш иң яхшы төбәк исемлегенә керә. 2010 елдан техника сатып алу һәм булганын газ ягулыгына җайлаштыру динамикасы 509 берәмлектән 10083гә кадәр арткан.

Пленар утырышта чыгышында Рөстәм Миңнеханов газ-мотор базарын үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә игътибар итте. Шуларның берсе – цифрлаштыруны гамәлгә кертү.

– Хәзерге вакытта Татарстанда газ-мотор ягулыгы базарының бердәм цифрлы платформасын булдыру буенча проект гамәлгә ашырыла. Цифрлы форматка күчү базарда катнашучыларның барысын да берләштерергә, яңадан җиһазландырылган транспорт чаралырын теркәү процедурасын гадиләштерергә, газ-мотор техникасын эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, – диде республика җитәкчесе.

Белешмә өчен

Санкт-Петербург халыкара газ форумы – шушы тармакка бәйле актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен әйдәп баручы мәйданчык. Фикер алышу буенча кабул ителгән карарлар дөньякүләм газ базарын формалаштыруга турыдан-туры йогынты ясый.

МӘҖБҮРИЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ

Балаларны мәҗбүриләп дингә җәлеп итү тыелачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында»гы канунга кертелгән төзәтмәләрне раслап, законга кул куйды.

Үзгәрешләрнең берсе – балаларны дини берләшмәләргә җәлеп итүгә чик куюга бәйле. Әлеге документ Татарстан Президентының рәсми порталында бастырылган. «Ватаным Татарстан»да ул якын көннәрдә басылып чыгачак.

«Балаларны кече яшьтән дини оешмаларга кертү, шулай ук үзләреннән, аларның әти-әниләреннән башка укыту тыела», – диелә законда.

Моннан тыш, дини оешмаларга үзләренә карата «Россиядә яшәүләре хупланмый» дигән карар чыгарылган затлар җитәкче була алмый. Шулай ук бу экстремистик эшчәнлек өчен хөкем ителгән гражданнарга да кагыла. Чит илләрдә укыган дин әһелләре Россиягә кайткач, кабат аттестация үтәргә тиеш булачак. Россия Юстиция министрлыгына дини төркем эшчәнлеген дәвам итү турында хәбәр итү вакыты да үзгәрә. Хәзер моны кимендә елга бер тапкыр эшләү тиешле.

«Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында»гы канунга төзәтмәләрне депутатлар Татарстан Дәүләт Советының 24 нче утырышында кабул итте.

pixabay.com

Сораштыру

ЮЛЛАМАДАН НӘРСӘ КӨТӘСЕЗ?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына еллык Юлламасыннан халык ни өмет итә? Шул хакта фикерләре, өметләре, тәкъдимнәрен сораштык.

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе:
– Мине кызыксындырганы – мәгариф, мәдәният, тел, милләт язмышы. Алар арасында иң борчыганы – милли мәгариф өлкәсе. Аңа игътибар күбрәк булсын иде. Ник дигәндә, милли мәгариф булмаганда, әдәбиятның да, мәдәниятнең дә киләчәге булмый. Гомумән, милләтнең язмышын милли мәгариф хәл итә.

Президентның Юлламасы җинисәп алдыннан уза. Әлеге чарага да игътибар күбрәк булсын иде. Чөнки җанисәптә халыкның ничә проценты үзен татар дип санаганы, аларның туган телләренә мөнәсәбәте ачыкланачак бит. Дөрес, республикада туган телләргә игътибар юк дип әйтә алмыйбыз. Махсус, Татарстан Президенты каршында Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе дә оешты, аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә бик күп чаралар үткәрелә. Алар барысы да бик кирәк. Әмма бу мәсьәләгә карашны тамырдан үзгәртмәсәк, аның нәтиҗәсе авыру кешегә авыртуны баса торган дару биргән кебек кенә булачак. Ә безгә дәвалары кирәк. Моның өчен Россия Думасына сайланган депутатларның активлыгы сорала. Без Думада уннан артык депутатыбыз бар дип горурланабыз горурлануын. Алар арасында Илдар Гыйльметдиновның гына милли мәсьәләләр буенча чыгыш ясаганын ишеткәнем бар. Башкаларын юк. Милли мәсьәлә аларны кызыксындырмыймы, әллә үзләренең язмышы турында гына уйлыйлармы? Бу безне бик борчый.

Рәмис ХӘЯЛИЕВ,
Кайбыч районы башлыгы урынбасары:
– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның республиканың эчке һәм тышкы хәле турындагы Юлламасын ел саен ниндидер бер киеренкелек белән көтеп алабыз. Билгеле, еллар берсенә берсе охшап килми. Яшерен-батырын түгел, бүген шактый катлаулы чор кичерәбез. Бу сәясәткә дә, икътисадка да, социаль мәсьәләләргә дә тәэсир итә. Республикада пандемиягә бәйле рәвештә туган икътисади кыенлыкларны җиңеп чыга алырбызмы? Халык белән эшләү, кешеләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту өлкәсендәге тотрыклылыкны саклый алырбызмы? Без нәкъ менә шушы сорауларга җавап булыр дип көтәбез. Һәм, миңа калса, Президент әлеге мәсьәләләргә һичшиксез тукталачак. Моннан тыш, Татарстанның берничә тапкыр Россия күләмендә тәнкыйтькә дучар булуын ишетеп беләбез, бу очракта Президент нинди күрсәтмәләр, киңәшләр бирер, чыгу юлларын күрсәтерме – бу турыда да сүз булыр дип өметләнәм.

Алия ШАГАЕВА, Балтач районының мәгариф идарәсе бүлеге башлыгы:
– Президентыбызның укытучыларга, мәгарифкә булган мөнәсәбәте безнең өчен бик кадерле һәм әлеге юнәлешкә аның игътибары зур. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе башкарган эшләр татар мәктәпләрен сакларга ярдәм итә. Авыл мәктәпләренә карашның яхшыруын сизәбез. Һәр елдагыча, быел да Юлламада мәгарифне үстерүгә урын булыр дип уйлыйм. Авыл мәктәпләрен, аграр юнәлешләрне тагын да үстерү буенча өметем бар. Бүген цифрлаштыру заманында мәгълүмати-коммуникатив чараларны ныгыту да кирәк. Химия, биология һәм башка фәннәрдән лабораторияләрнең, заман таләпләренә туры китереп, җиһазландырылуын телəр идем.

Илдус ХАТЫЙПОВ, мал табибы:
– Президент Юлламасыннан авыл хуҗалыгындагы проблемаларга бәйле берәр сүз, күрсәтмә булсын иде дип көтәм. Әйтик, ташландык җирләр турында. Нишләп сукаламыйлар яисә, урман фондына күчереп, урман утыртмыйлар? Күбесе шәһәр янында бит. Быелгы кебек, яшелчә проблемалары булмасын өчен дәүләт программасын булдыру кирәктер. Игътибар юнәлтерлек башка мәсьәләләр дә бар. Районнарда оптимальләштерү ясый башларга кирәк. Бала табу йортлары, мәктәп, хастаханәләр кимесә дә, районда чиновниклар кимеми бит. Мәдәният, белем бирү һәм башка идарәләр 3–4 районга бер булырга тиеш дип саныйм.

Гүзәл ТӨХВӘТОВА,
Габдулла Тукай әдәби музее директоры:
– Нинди генә өлкәне алсак та, милли мәсьәләне урап узып булмый. Дәүләт күләмендә мәктәпләр белән мәдәни оешмаларны якынайта торган махсус программалар булсын иде дип телим. Фәнгә игътибар кирәк, аның кайбер тармакларының хәле сөендерми. Шәхесләргә игътибар артсын иде. Без аларны юбилейдан юбилейга гына искә төшерәбез.

Альбина НАСЫЙРОВА, «Бала-сити» мультилингваль балалар бакчалары җитәкчесе:
– Минем кадрлар мәсьәләсенә игътибар юнәлтәсем килә. Бигрәк тә балалар бакчаларына. Әйтик, няняларның хезмәт хакы 10 мең сум тәшкил итә. Ул иртәнге сигездән кичке алтыга кадәр эшли. Балалар саны һәр төркемдә утызга якын була. Билгеле, мондый хезмәт хакына кечке тәрбияче табу бик читен. Нәтиҗәдә балалар бакчаларындагы кадрлар мәсьәләсе киеренкелеге туа. Президентыбыз бу мәсьәләгә игътибар итсен иде. Тагын бер зур проблема – әхлак, тәрбия мәсьәләләренең арткы планга чигерелүе. Соңгы вакыйгалар, 175 нче гимназия, Пермь фаҗигасе балаларга игътибар җитмәвен күрсәтте. Һәр мәктәптә көчле психологларның эшләве кирәк, шунсыз булмый.

Айдар ШӘЙХИН

БАШ ХӘРЕФ ТУРЫНДА

Дүшәмбе кичендә дөньяда берничә сәгатьлек «афәт» булып алды: иң таралган аралашу чаралары булган Ватсап, Фейсбук һәм Инстаграм эшләми торды. Бу хакта язмаган сайт, газета һәм журнал калмагандыр инде. Шул бихисап яңалык текстларына күз салганда, кайбер каләм ияләренең бу сәхифәдә бер ай элек чыккан дәресне үзләштермәгәнләре ачыкланды. Сүз «ватсап»лар турында бара.

Менә бер җөмлә: *Душәмбе көнне фейсбук платформалары, шул исәптән инстаграм социаль челтәре һәм ватсап мессенджеры эшләмәде.*

Татар теле дәресләрен искә төшерик: бер төрдән булган предметлар һәм затларның берсенә генә бирелгән исем **ялгызлык** исем дип атала. Ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, ә аерым очракларда куштырнаклар белән аерылып куела.

Фейсбук, Инстаграм, Ватсап – болар барысы да ялгызлык исемнәр, чөнки алар, бердән, конкрет бер сервис исемнәре, икенчедән, сәүдә маркалары буларак закон тарафыннан яклапган атамалар да әле. Шуңа күрә бу сүзләрне баш хәрефтән язарга кирәк.

Бу очракта куштырнаклар да кую дөрес булыр иде: *«Инстаграм» социаль челтәре, «Ватсап» мессенджеры*. Һәрхәлдә, матбугатта басылган текст бу кагыйдәләргә буйсынырга тиеш дип саныйм.

Инстаграмның үзендә кеше ничек тә яза ала. Аның дөрес язу-язмавы аның шәхси эше, үз намусы, үз йөзе. Әмма матбугат хаталы язуны пропагандаларга тиеш түгел, әлбәттә.

ИРЛЕК / ИРЛЕЛЕК

«Ирлелек бөтен эшне боза» дигән җөмләгә тап булгач, башны бик каты эшләтергә туры килде. Нәрсә ул ирлелек? Татар телендә мондый сүз әлегәчә юк иде дисәм, ялгышырмын. Сүз төзелешеннән чыгып, мәгънәсен болай дип аңлатып булыр иде: ирлелек – ирле булу халәте, ситуациясе. Әмма югарыдагы җөмләдә башка вакыйга сурәтләнә иде. Анда сүз *ирлек* сыйфатлары турында бара. Күчерелмә мәгънәдә ирлек «батырлык, кыюлык, чын иргә хас булган сыйфатлар» дигәнне аңлата (2013 елгы «Аңлатмалы сүзлек»). *Ирлелек* исә татар телендә бер очракта гына кулланыла: күп ирлелек (полиандрия).

Димәк, югарыдагы очракта *бөтен эшне ирлек бозды*. Гомумән, «-лелек/лылык» конструкцияләре бик алдавыч була, алар белән сак эш итәргә кирәк.

P.S. «Хаталар өстендә эш» сүзтезмәсе татар телендә гомуми кулланылышка кергән һәм хата дип саналмый. Хәлбуки бу – рус теленнән калька рәвешендә тәрҗемә ителгән гыйбарә. **Хаталарны төзәтү** дип әйтү татарчарак яңгырар иде.

Әйтеп кенә бактым

Чир

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Адәм баласы барына да күнегә шул. Пандемия афәтенә дә ияләшеп киләбез, бармы ул коронавирус дигәннәре, юкмы – артык исебез китми башлады кебек. Үзебезнең даирәдә берәрсе җан тәслим кылса, бераз өркеп алабыз үзе. Әмма курку озакка бармый.

Бу язмага тотынып алдыннан таныш табибларым белән сөйләшеп алдым. Заманында Республика клиник хастаханәсендә пульмонолог булып эшләгән Нәкыйп Каштанов әйтүенчә, бүгенгә вирусны юкка чыгара ала торган дару юк. Шуңа күрә бердәнбер юл – саклану. Ягъни вакцинация ясату, халык күп җыелган урыннарга бармау, дөрес туклану. Икенче танышым, хирург Әнвәр Вафин, таләпләрне кырысландыру кирәк, ди. Ул халыкның ким дигәндә 60 проценты вакцинация ясатырга тиеш дип узган ел ук әйткән иде. Кая ул алтмыш! Шунын яртысына да җитә алганыбыз юк. Моңа кем гаепле? Табиблармы, җитәкчелекме? Шәхсән үзем ваемсызлык дияр идем. Бу – иң куркыныч чирләрнең берсе, чөнки бу чирдән үзен генә зыян күрмисең. Израильдә халыкның 80 проценты вакцинация ясаткан. Яһүдләр үз кадерләрен үзләре белә торган халык шул.

Кызганыч, ваемсызлыктан дәвалый торган дару юк шул, нәкъ таҗвирустан кебек. Димәк, аңа да пандемиягә каршы кулланган чаралар кирәк. Болар – чикләү, мәҗбүрилек, карантин. Башкача булмый.

Күпме танышыма, дусларыма шалтыраттым, вакцина кадатканмы, юкмы икәнлекләрен сораштым, бик сирәге генә, әйе, дип куйды. Башкалары ничек? Баксаң-күрсәң, вакцинация ясаткан кешеләр дә авырый икән бит, фәлән кеше шулай дип әйткән, имеш. Без бүгенге вазгыятьне әнә шул имеш-мимешләр аша гына күзалларга өйрәнеп беттек кебек.

Рәсми статистикага килсәк, Россиядә вакцина ясатканнарның 2 проценты гына вирус йоктыра, аларның да күбесе – бер генә тапкыр вакцинация ясатучылар. Бу – Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко китергән саннар һәм алар көне-сәгате белән тагын үзгәрергә мөмкин. Аннан соң статистика ул күпмедер дәрәҗәдә сәясәт тә әле. Шуңа да карамастан без аны кабул итәргә тиеш. Чөнки алар фәлән кешедән ишеткән саннар түгел. Без: «Язмыштан узмыш юк. Ходай ничек язгандыр инде», – дип сөйләнергә яратабыз. Әле бит аның «Аллага ышан, үзеңгә таян» дигәне дә бар. Шөкер, мин дә, хатыным да вакцина ясаттык, хәтта башка шәһәрдә яшәүче улыбыз да. Аны берәү дә мәҗбүр итмәде. «Бер-беребезгә йога күрмәсен, әти», – диде. Һәркем үзенең туганнары, якыннары турында шулай кайгыртсын иде ул. Алда безне төрле сынаулар, хәвефләр көтәдер, әмма бүген тыныч күңел белән яшибез, монысы да зур нәрсә. Бит курку, шикләнү үзе дә – чир, яңа чирләр китереп чыгаручы чир дип әйтүем.

РУХЫҢ САУМЫ, КЕШЕМ?

Ел саен традицион рәвештә 10 октябрьдә Бөтендөнья психик сәламәтлек көне билгеләп үтелә. Мондый даталарның әһәмиятен Көнбатышта, проблеманы билгеләп, аңа каршы көрәшү дә дип саныйлар бит инде. Әмма дә ләкин нәкъ менә Көнбатыш илләрендә кешеләрнең психикасы аеруча нык какшый.

Үткән елларның статистикасына карасак, үзләрен икътисади яктан алга киткән дип санаган илләрдә психик тайпылышлар аеруча күп күзәтелүен күрәбез. Суицид буенча лидер булган ун илнең тугызы – Европада, һәр сигез кешенең берсе диярлек депрессиядән һәм хәвефләнеп яшәүдән шул кыйтгада интегә. АКШ та Европадан калышмый, әлбәттә. Хәтта лидерлыкны үз кулында тотарга тырыша. Әле соңгы көннәрдә генә «Телеграм» каналга Америкадан соңгы статистика мәгълүматлары килеп төште. Федераль тикшеренүләр бюросы (ФБР) АКШта 2020 елда үтерүләр саны 29,4 процентка артты дип хәбәр итә. Алдагы елларда да ул илдә җан кыюлар саны аз булмавын исәпкә алсак, үтереш янкилар өчен көндәлек гадәти хәл булуын төшенү кыен түгел. Юк, Европаны яисә Американы аерып алып куймыйм һәм аларданы хәлләрнең начар булуына сөенеп тә язмыйм бу юлларны. Безнең үзебездә дә вазгыять шул чама. Суицидлар, үтерешләр, кешеләрнең бер-берсен түбәнәйтеп ләззәт алырга тырышулары прогрессия тәртибендә арта. Вәләкин бу психология Көнбатыштан иңә безгә. Юләр идеяләрнең, булмаган нәрсәләр белән саташуларның генераторы шуларда. Әле җитмәсә, алар шуны, демократия таратабыз дип, бөтен дөньяга көчләп тагарга маташалар, буйсынмаган илләрдә «террорга каршы» көрәш уйлап табалар һәм либераль җәмгыятьләргә ул «көрәш» бик куәтле бумеранг булып китереп суга.

Әйдәгез, карыйбыз: нәрсәне алга үткәрергә җыена Көнбатыш идеологлары. «Зәңгәр»ләр һәм «алсу»ларның өстенлеген. Менә Венгриядә бу көздә генә мәктәпләрдә балалар өчен ЛГБТ пропаганданы тыю турында закон кабул иттеләр. Евросоюз дәүләте бит инде. Игътибар итегез: гомосексуализмны илдә тыю турында түгел канун, ә аны балалар арасында пропагандалауны рөхсәт итмәү генә күздә тотыла. Европарламентта моңа кискен каршы чыктылар: «Безнең кыйммәтләргә каршы килә», – дип, Венгрияне Евросоюздан чыгару турында да сүз кузгаттылар хәтта.

Соңгы көннәрдә генә бер ана Америкада мәктәп китапханәсендәге дәреслеккә нәфрәтләнеп администрациягә килде һәм китапны ачып педагогларга аннан өзекләр укый башлады. «Тукта хәзер үк, балалар ишетә», – дип тыярга тырыштылар аны. Ананың китапның мәктәп китапханәсендә иркен кулланылышта булуын әйтүенә: «Ул өлкән яшьтәге балалар өчен», – дип акландылар.

Ирләр юк, хатын-кызлар юк дип саташу, балаларның җенси үсешен гормональ дарулар ярдәмендә туктатып, малайлардан – кызлар, кызлардан малайлар ясарга омтылышның киң җәелүе – либераль демократиянең тагын бер «уңышы». Бу шул дәрәҗәдә аек акылга сыймый, хәтта соңгы көннәрдә генә бер төркем француз табиблары һәм галимнәре: «Балаларга җенси үсеш блокаторлары бирү һәм аларның җенес әгъзаларында гарипләндерә торган операцияләр ясау – акылдан язу», – дип белдерделәр. Илледән артык табиб, юрист, психиатр һәм башка тармак галимнәре имзалаган «Ачык хат»та: «Трансгендер бала эмансипациясе хакына барган җитди хәрәкәтне күреп, без бүтән эндәшми кала алмыйбыз», – дигән сүзләр бар. Әмма идеологияне билгеләүче сәясәтчеләр бирешми. Шушы көннәрдә генә Европа Советы комиссиясе Россияне ике рекомендацияне үтәмәүдә гаепләде. Рекомендацияләрнең берсе – традицион булмаган җенси мөнәсәбәтләрне мәктәпләрдә балалар арасында пропагандалау. Бу турыда озак сөйләшергә мөмкин булыр иде. Без бер генә фактны китерик тә башка юнәлешкә күчик.

Америка вице-президенты Камала Харрисның үги кызы Элла Эмхофф GQ (ирләр өчен журнал) редакторы Сэм Хайн белән урамнан җитәкләшеп узды. Хәзерге җәмгыять өчен бу гаҗәп түгел, билгеле. Гаҗәбе шунда: Сэм Хайн – ир кеше – итәктән, Элла Эмхофф – галстуклы. Хатын-кыз дигән сүзне рәсми рәвештә тыюга таба хәрәкәт көчле. Соңгы тәкъдим: гүзәл затларны хатын-кыз әгъзалары булган (төп әгъзаның исеме әйтелә инде, хатын-кыз дигән сүзне әйтергә ярамый бит) кеше дип атарга. Ирләрне бала табарга һәм имезергә өндәп сатащулар турында әйтеп тә тормыйк инде. Хәзерге медицинаның моны оештырырга көче җитә, дип әйтәләр. Менә бу мәгълүматларны карагач, Көнбатышта элиталарның түбәсе тәмам кыйшайган, аларның идарәсенә буйсынган халыкның психикасы 99 процентка сәламәт түгел дигән фикер үзеннән-үзе сорала. Ничу монда статистиканың депрессияләрдән интегүче кешеләр турында саннарын карап утырырга.

Депрессия дигәннән, анысының төп сәбәбе, әлбәттә, кешеләрнең матди байлыклар артыннан кууы. Тәмлерәк һәм күбрәк ашарга омтылыш, мәсәлән. Бу юлларны язар алдыннан дөнья статистикасын ачып куйдым. Бу елның 6 октябренә кадәр бер миллион 907 меңнән артык кешенең эчеп үлүе, 817 меңнән артык кешенең үз-үзенә кул салуы турындагы мәгълүматларны сикереп уздым да (32 миллионнан артык аборт бар әле тагын), симезлек белән бәйле проблемаларга килеп туктадым. Авырлыгы артык булучылар саны 1 миллиард 716 миллионнан ашып китә. Симезлеге чиргә һәм газапка әйләнүчеләр саны – 793 миллионнан артык. Болар үлмиләр дә, яшәмиләр дә. Мин күптән түгел генә тәкъвалыгы белән танылган бер мөселман галименең сүзләрен үзем өчен язып куйдым. Кальбе чирле кешеләр турында ул: «Кеше аңышмастан үзе өчен зыянлы булган нәрсәләрне эшли. Мәсәлән, бирәнлек һәм әйбергә табынудан интегә. Туйганчы ашамый яисә үзе бәйлелеккә төшкән әйбергә ия булмый торып газап чигүдән туктамый. Һәм шул факт таң калдыра: куллану ихтыяҗын канәгатьләндерү кешене газаптан коткармый, газапны көчәйтә генә. Бәйлелеккә төшкән кеше ашаганда да, ашамый торганда да интегә», – ди ул. Никадәр хак сүзләр!

2010–2015 елларда Уругвай Президенты булып торган Хосе Мухикины «иң фәкыйрь Президент» дип йөрттеләр. Ул дәүләт резиденциясеннән баш тартып, су кертелмәгән авыл өендә яши, иске машинада йөри, урлашмый гына түгел, хезмәт хакының 90 процентын садака итеп өләшә. Хосе Мухики бәхетле булып яшәү кагыйдәсенә ярарлык сүзләр әйтә: «Я сез азга ия булган хәлдә өстегезгә артыгын өйми генә бәхетле, чөнки бәхет ул – эчтә (йөрәктә), я сезнең берни дә барып чыкмаячак. Бу фәкыйрьлекне аклау түгел. Тыелуны аклау. Әмма без бертуктаусыз үсеш эзли торган куллханучылар җәмгыяте төзедек. Үсеш булмаса, бу – фаҗига.

Без чамасыз ихтыяҗлар тавын уйлап чыгардык. Сез бертуктаусыз нәрсәдер сатып алырга һәм ташларга тиешсез. Без үзебезнең гомеребезне шулай итеп вагабыз. Нәрсәдер сатып алганда, без бит акча белән түләмибез. Без үткән гомеребез белән түлибез. Без нәрсәдер сатып алу өчен эшләгән вакытыбыз белән түлибез. Аерма шунда гына: гомерне сатып алып булмый. Гомер үтә. Һәм бу – котчыккыч», – ди ул һәм аз гына акчага яшәп тә, бәхетле булырга мөмкинлеген исбатлап күрсәтә.

Менә кешеләр ни өчен хакимлеккә омтыла? Күбрәк умырып алып, күбрәк байлыкка ирешү өчен. Испаниядәге мөселман дәүләте Андалусия белән 50 ел идарә иткән һәм илнең чәчәк атуына ирешкән Габдрахман III Андалуслы дигән хәлиф үлгәч, ул язып калдырган хатны табалар: «Мин идарә иткәндә бәхетле булган һәм хәсрәтләнмәгән көннәр фәлән елның фәлән аендагы фәлән көн», – дип бәхетле көннәрен исәпләп барган ул. Санап караганнар: илле елга ундүрт көн җыелган. Хакимлек һәм байлык кешене бәхетле итми, хәсрәткә генә сала. Менә шуны аңламаганга күрә «Психик сәламәтлек көне» дигән көннәр уйлап чыгарырга туры килә инде. Әмма ул датаны билгеләп үтү аз гына да булышмый. Елдан-ел түбәсе кыйшайганнар саны арта бара. Һәм без бикле ишекләр артында, сак хезмәте яллап, качып яшәргә мәҗбүр булабыз.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Бер авызы пешкәч, кабат өреп каба белми халык. Акча мәсьәләсендә аеруча. Быелгы җәйнең финанс пирамидалары белән бәйле гыйбрәтле хәлләре күпләр өчен сабак булырлык иде югыйсә. Шушы көннәрдә Казан урамнарында янә «МММ» рекламасы пәйда булган. Сергей Мавроди тарафдарлары кабат җиңел акча эшләргә өйрәтә башлаган дигән сүзме бу?

Илдар Мөхәммәтҗанов

МАВРОДИ МИРАСЫ

Мавро үсә, син байыйсың

10–15 миллионлап кешене кәкре каенга терәгән, 50 кешене үз-үзенә кул салуга җиткергән Мавроди системасы озак вакытка халыкның инвестицияләүгә булган кызыксынуын һәм ышанычын киметеп торды. Дистә еллардан соң кабат шушы системаны кулланучылар уяныр дип кем көткән иде икән?!

Хәйриячелек оешмасы, халык банкы, ярдәм кулы сузучылар. Мавроди системасын торгызып җибәргән кешеләр иске-яңа «МММ»ны шушы сүзләр белән тасвирлый. Казан һәм башка зур шәһәрләрнең элмә такталары, баганаларында, машина, автобус тәрәзәләрендә җиңел генә табыш алырга чакырган рекламалар күренә башлады. Болары «Телеграм» социаль челтәрендәге каналда махсуслашкан, QR-кодлары да бар. Акча эшли башлау өчен «Телеграм-бот» аша теркәлү узасы икән.

Шунысына да игътибар итәргә кирәк: яңа «МММ» яшьрәкләргә йөз тота. Ник дигәндә, замана инструментларының барысын да кулланалар бит: «Тик-ток», «Телеграм», «Ютуб» каналлары бар, шулар аша элемтәдә торалар. Аннан, Мавроди нәрсә белән танылганын белмәгән буын да үсеп җитте бит.

«МММ – 2021»не оештыручылар аны «Мавроди исемендәге үзара ярдәмләшү кассасы» дип атый. Ул инде узган елның май аеннан бирле эшләп килә икән. Схемасы болайрак: «мавро» дигән валюта сатып алырга кирәк. Аның курсы ай саен чагыштырмача 5–15 процентка үсә, имеш. Аз гына акча салсаң да, күп итеп табыш алып булачагына ышандыралар. Исәпләп карау өчен «бәхет калькуляторы» да бар. Катнашу өчен кимендә 50 доллар (хәзерге курс белән – 3500 сум. – **Ред.**) акча кертергә кирәк. Бу акчаны уртак банк исәп-хисап счетына күчерәсе. «Мавро»дан теләсә кайсы вакытта баш тартып була икән. Түләүләрне биредә «ярдәм» дип атыйлар. Күбрәк акча кертсәң, аларны биткоин-янчыкка кабул итәләр. Проектка яңа килеп кушылганнар өчен төрле кызыксындыру чаралары үткәрелә. Әйтик, бер мең сумга «мавро» сатып алганнарга бер атнадан соң икеләтә «күчтәнәч» бирәләр.

«Телеграм» каналда кертемчеләрнең акчасы ышанычлы кулларда дип үгетлиләр. Хуҗалары бар акчаны җыеп, качарга уйласа да, бу – мөмкин түгел, чөнки малны «дистә»ләр буенча бүлгәләгәннәр, имеш.

«МММ – 2021» кертемчеләрне алдан ук кисәтеп тә куя: әлеге системаның финанс пирамидасы булмавында бернинди гарантия дә юк. «МММ»да катнашып, тулаем барысын да югалту ихтималы барлыгын онытмаска кушалар.

Проектта катнашучылар аның изге нияттән барлыкка килүенә ихластан ышана (язма әзерләнгән вакытта бу «Телеграм» каналда 2 меңләп кеше теркәлгән иде. – **Ред.**). Беравыздан: «Оештыручыларның табыш алу, баю нияте юк», – диләр. Бу – кешеләрнең матди хәлен яхшырту мәйданчыгы, имеш. Тик «Френдекс», «Финико» һәм башка пирамидалар да «сезгә ярдәм итәбез» дигән тәмле сүзләр белән буш вәгъдәләр ашатты түгелме?

САН

2021 елның беренче яртысында Россия Үзәк Банкы 146 финанс пирамидасын ачыклаган. Бу узган елга караганда бер ярым тапкыр күбрәк. Чынлыкта исә аларның саны тагын да күбрәк булырга мөмкин, ди белгечләр. Мошенниклар инвестиция компанияләре, кредит кооперативлары һәм башка финанс оешмалары исеме астында да оста яшеренә.

Әлбәттә, майлы калҗаның бер өлешен тешләп калучылар да булгандыр. Тик ярдәменнән битәр зыяны күз яшьләре белән әле дә юып бетерә алмаучылар бер-ике генә дә түгел бит.

Югалтуларга китерәчәк адым

Финанс пирамидасыннан зыян күрүчеләр турында күпме генә сөйләсәк тә, киңәшләр биреп торсак та, беркатлылык корбаннары кимеми.

Хокук һәм финанс белгече Ләйсән Харисова әйтүенчә, җәен бер-бер артлы юкка чыккан финанс пирамидаларыннан зыян күргән кешеләр яңаларына бик тиз кызыгырга мөмкин. Аның сүзләренчә, бер төр пирамидаларның таркалуы башка финанс компания-оешмаларны уятты.

– Алар зыян күргән кешеләргә: «Югалткан акчагызны кире кайтарабыз», – дип вәгъдә бирде. Моның шарты: таркалган финанс пирамидасына кертелгән сумманың фәлән процентын түләү. Кеше инде моның мөмкин хәл икәненә ышана. Бер генә югалту җитмәгән, шул рәвешле икенче мәртәбә дә бернәрсәсез калалар. Мондый ышанучан кешеләр шәхсән минем тәҗрибәмдә дә еш очрады. Мондый очракта аларга ничек булышырга да белмисең. Югыйсә, шикле финанс оешмаларына акча кертмәгез, дисең, финанс пирамидалары турында кисәтәсең. Тик кеше барыбер өметләнә, – ди белгеч.

Ләйсән Харисова мондый шикле проектларга тиз бирешүчән кешеләр төркемнәрен атады.

– Иң элек, андый пирамидаларда азарт яраткан кешеләр катнаша. Алар зур суммалар белән уйный. «Хайп» проектларга акча кертә. Моннан тыш, мондый урыннарда җиңел акчага кызыгучы, бармакка бармак сукмыйча табыш алырга теләүчеләрне очратырга була. Болар – аз акча салып, күпкә өметләнүчеләр. Тагын бер төркем – кызыксынучылар. Кеше кергәч, мин дә керәм, диючеләр бу. Шунысы начар: менә бу категориягә караган кешеләр, җиңел акча тәмен татып, тагын да күбрәк акчасын шунда ташый башлый. Чир кебек бу, азарт хисе уяна. Бер компания ябылгач та, бер-ике атна тәшенкелектә булып, бераздан башка компаниягә бар булган акчасын тапшырган кешеләрне беләм. Андый кешеләрне ничек кисәтергәдер – белгән юк, – ди белгеч.

Тиз акча булмый. Бар икән, ул мөлкәтнең дә кемнеңдер күз яше, үпкәсе, рәнҗеше белән тупланган булуы ихтимал. Ләйсән Харисова да шул фикердә. «Кеше килачәген уйласын иде. Пирамидадагы акча яхшы акча түгел. Соңарып булса да, моны аңлаучылар бар», – ди ул.

Татарстанның атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре, психолог, педагогика фәннәре кандидаты Ольга Ажимова да кырыгалдарлар капкынына ешрак нинди кешеләр эләгүе турында искә төшерде. «Беренчесе – «бәйле уенчылар». Алар өчен азарт уяткан процесс үзе мөһим. Бу алар өчен эмоциональ наркотик кебек. Ә җиңелү тагын да көчлерәк хис-кичерешләр бирә, адреналин өсти. Икенче категория – «тыныч уенчылар». Алар уен кануннарын белә, процессның нечкәлекләрен аңлый, барлык шикле урыннарын анализларга тырыша, күбрәк табыш алып калу мөмкинлеген карый. Бу кешеләр еш кына тотрыклы хезмәт хакына ия, ә пирамидага керү – алар өчен хобби гына. Аларга шунсыз күңелсез булыр иде. Өченче категория – «очраклы уенчылар». Вакыт-вакыт алар, артык акчасы булган очракта, финанс пирамидасына керә ала. Боларның финанс хәле тотрыклы, һәм берничә мең сум акчасын югалтып кына алар артык зыян күрмәячәк. Табыш алсалар, бу – уңыш. Дүртенче категория – зыялы, акыллы кешеләр. Аларның матди хәле дә яхшы, җәмгыятьтә абруе да бар. Шушы категориягә, гадәттә, аз хезмәт хакы алып, көндәлек эшеннән арыган, рухи һәм һөнәри яктан «янган» кешеләр керә. Шунысын да әйтергә кирәк: бу кешеләр беркайчан да үзләренең җиңелүләрен таныp, полициягә гариза тотып бармаячак. Иң элек килеп чыккан вазгыятьтә алар үзләрен гаепле дип санаячак. Моңа өстәп, башка кешеләрне төп башына утырткан өчен дә намуслары тынгы бирмәячәк. Тагын бер категория – финанс тозагына эләгеп, соңгы акчасын да югалтырга әзер кешеләр төркеме. Алар бүтәннәрнең уңышын күреп, тиз бирешә», – дип аңлатты белгеч.

Ольга Ажимова әйтүенчә, кешегә, асылда, артыгы кирәкми дә. «Артык күп байлыкка кызыгу – явызлык ул. Аның өчен барыбер түлисе. Кайдадыр өстәлә икән, димәк, икенче урында кими, шушы кагыйдәне истә тотсак икән», – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КИҢӘШ

Кырыгалдар капкынына эләкмәс, финанс мәсьәләсендә белемнәрне арттыру өчен, бушлай белем алу мәйданчыклары бар. Шуларның кайберләре:

- **dni-fg.ru**
- **4brain.ru/finance**
- **finprosto.ru**
- **znaikak.ru/business**
- **fingramota.org**

«КАБАК КОЛОРАДО КОҢГЫЗЫН БЕТЕРӘ»

БАЛТАЧ РАЙОНЫНЫҢ БОРНАК АВЫЛЫНДА ЯШӘҮЧЕ САЛИХҖАН ӘХМӘТХАНОВ БЫЕЛ БАКЧАСЫННАН БИШ ЙӨК МАШИНАСЫ КАБАК ҖЫЕП АЛГАН

Балтач районының Борнак авылында яшәүче Салихҗан Әхмәтхановның кабак патшалыгында булып кайтканнан соң бакчада ут янып утырган гап-гади кабакка бөтенләй башка күзлектән – хөрмәт белән карый башладык без. «Патшалык» диюем дә арттыру түгел. Салихҗан Әхмәтханов быел бакчасыннан биш йөк машинасы (!) кабак җыеп алган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Салихҗан абый профессиональ бакчачы да, бу юнәлештә нииндидер махсус белем туплаган белгеч тә түгел. Юкны бар итәргә өйрәнгән, биргәнне көтеп утырмыйча, булганыннан бәрәкәт ясап тормыш алып барырга күнеккән тырыш авыл халкының бер вәкиле ул. Гомер буе әретеп ябыштыручы булып эшләгән Салихҗан Әхмәтханов ун ел элек күпләп кабак үстерүгә керешкән. «Шулай бервакыт эш буенча күрше Янгул авылында яшәүче танылган «халык синоптигы» Әмир абый Шәрәфиевкә барырга туры килде. Сүз ара сүз китеп ул: «Бер чиләк кабак бер чиләк фуражны алмаштыра. Микроэлементлар ягыннан да ашлыкка караганда файдалырак ул», – дип куйды. Аның шушы сүзләрен истә тотып кабак утырта башладым. Ян бакчалардан тыш басуда сигез гектар җирем бар. Кабак утыртканчы, шунда солы да чәчеп карадым. Әмма аны үстерү бик авыр, чыгымлы булып чыкты. Ә кабакның бер мәшәкате дә юк», – дип искә алды ул эшкә тотынган гына елларын.

Шул көннән башлап малларга ашату өчен бакчасына күпләп кабак утырта башлый Салихҗан абый. Берсе – 18, икенчесе 20 сутый булган ике зур ян бакчасының берсенә – бәрәңге, икенчесенә кабак утырталар. Һәвәскәр кабакчы ике елдан ике елга аларның урыннарын алыштырып тора икән. «Кабак колорадо коңгызын юкка чыгара. Болай эшләгәндә җир дә ял итә», – ди ул. Ни гаҗәп, бәрәңге уңышы мактанырлык булмаган быелгы җәйдә Салихҗан абыйның бакчасында анысы да ишелеп уңган. Ике «ГАЗ-53» машинасы бәрәңге җыеп алган алар. Гаилә башлыгы монда да кабакның файдасын күрә.

– Бер машина бәрәңгене килосын 25 сумнан сатып җибәрдек. Берсен үзебезгә калдырдык. Бәрәңге ел саен әйбәт була безнең. Ашлама керткән юк. Тиресне түгәм дә сукалап куябыз, шуның белән шул. Бәрәңге җирен кабак белән чиратлаштырып торуның да файдасы зур. Җирне болай уйнатып тору чүпне дә киметә, – ди Салихҗан абый.

Киң дала кебек җәелеп яткан ян бакча башыннан инеш ага аларның. Салихҗан абый шунда үзенә ял урыны да әзерләп куйган. Шундагы эскәмия янында җәй буе кармагы ята икән. Эштән арып киткән арада балык чиртеп килә гаилә башлыгы.

Корылык та куркыныч түгел

Әхмәтхановлар бер сыер, ике бозау, 13 баш сарык, каз, үрдәк, тавык-чебеш асрый. Мондый зур хуҗалык тоткан кешеләргә быелгы җәй аеруча зур сынауга әверелде. Корылык аркасында печәне дә, ашлык уңышы да ташка үлчим генә булды. Шул сәбәпле быел ашлык та алтынга тиң. Бүген аның уртача бәясе 18 сумнан йөри. Салихҗан абыйга исә елның-елында корылыгы да, ашлыкның кыйммәт, печәннең аз булуы да куркыныч түгел. Бакча тутырып үскән кабак коткара аны.

Көздән җыелган уңышны малларга кыш буе – 1 февральгә кадәр ашатып чыга алар. Кабакны аннан да соңракка калдырырга ярамый икән. Ник дигәндә, ул вакытка инде кабак эчендә соклар йөри башлаган була. «Андый кабак ашаган мал агуланырга мөмкин, – ди Салихҗан абый. – Малларга кабакны көн саен иртә-кич берәр чиләк бирәм. Артыгы ярамый. Яшь бозауларга турап салам. Сыер, үгезләргә балта белән генә чабам да шул килеш ашап бетерәләр. Кабакның чери башлаганнарын да әрәм итмибез. Турап, прачкада пешереп, казларга ашатабыз».

Кабак запасы мулдан булгач, Әхмәтхановларга ашлыгын да аз сатып алырга туры килә. Аннары кабак ашап үскән мал бәрәкәтлерәк тә була икән. «Ул малларны бик яхшы симертә. Кабак ашап үскән малның мае да сары була. Сыерның сөтен дә арттыра. Узган ел март аенда кабак ашатмый башлагач, көн саен 10 литр сөт биргән сыерның сөте 4,5 литрга кимеде», – ди гаилә башлыгы.

Соң утыртсаң да җитешә

Быел аеруча да мул бакчалар белән танышканнан соң Салихҗан абыйның кабак патшалыгына үтәбез. Элеккеге авыл өен хәтерләткән сарайның һәр бүлмәсе шыплап кабак белән тулган. Бер – бүлмәдә кабакның эреләре генә, икенчесендә – уртачалары, өченчесендә вaклары саклана. Сарылары малларга ашатырга, яшелләре ризык әзерләргә яхшы икән.

Сүз уңаеннан, шунысын да әйтеп китик, Салихҗан абыйның остханәсенә әверелгән бу өй бик тарихи да булып чыкты. Заманында биредә «Борнак» колхозын җитәкләгән, узган чакырылышларда Дәүләт Думасы депутаты Фатыйх Сибагатуллин, аннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов гаиләсе белән яшәгән. Алардан соң башка белгечләр дә гомер иткән. Армиядән кайткач, аны Салихҗан Әхмәтханов гаиләсенә биргәннәр. Шушында яшәп, янәшәдә генә яңа йорт җиткергәннәр.

– Көннәр суыта башлау белән сарайдагы кабакларны өй астына кертәм. Начарларын алданрак турап ашатам. Ныгракларын сакларга калдырам. Кыш буе ашатырга җитә. Декабрь аенда ашатырга дигән эре кабакларны чоланга кертеп куйдым инде, – ди ул. Бакча тутырып кабак үстерсәләр дә, Әхмәтхановларның кабакка әллә ни исләре китми икән. Кабактан ризыклар бу гаиләдә бәйрәмнәрдә генә әзерләнә.

Салихҗан Әхмәтханов ун ел дәвамында кабак үстерүнең бик күп серләренә төшенгән. «Кабакны 1 майда ук утыртырга ярамый. Майның ахырына туры китерергә кирәк. Иң соңгы кырау гадәттә 9–12 июньдә төшә. Кабак шуңарчы тишелеп чыкмаска тиеш. Шуңа күрә аны 20–25 майларда утыртам. Кырау эләксә, кабак уңышы булмаячак дигән сүз. Ашыкмаска кирәк, соңрак утыртсаң да җитешә ул», – ди Салихҗан абый.

Кабак салкынны ярата

Кабакны аерым сортларга гына аерып та утыртмыйлар икән. Барысы да – ун ел дәвамында үзләре ясаган орлык, кемдә нинди сорт бар, шулардан җыеп алынган. Дөрес, Салихҗан абый быел кибеттән дә бер-ике төрле яңа сорт сатып алып утыртып караган булган. «Галателло» дигәненең ун орлыктан берсе генә тишелгән. «Медовый» дигән сорт тәмле, баллы булса да, озак сакланмый, тиз бозыла икән. Елның-елында Салихҗан абыйдан кабак сатып алырга киләләр. Быел килосын 15 сумнан озаткан ул. Чагыштыру өчен: кибетләрдә кабак бәясе ел әйләнәсе 60–70 сумнан төшми. Теләге булган кешегә кабак сатып та яхшы гына табыш алырга мөмкин, димәк.

– Декабрь аенда өч-дүрт кабакның орлыгын алам, яхшылап киптерәм дә киндер капчыкларга салып салкынга чыгарып куям. Кабак орлыгы салкынны ярата. Кабакны өмә ясап утыртабыз, өмә ясап җыеп та алабыз. Бәрәңге утырткандагы кебек буразна сызабыз, хатын-кызлар бер рәткә тезелеп басалар, орлыкны төртеп, таптап куялар. Алганда йөрергә җиңел булсын өчен кабак сабакларын чабып чыгам да эше бетте. Кабакның башка бер мәшәкате дә юк. Ашлама да, бернинди тәрбия дә, техника да кирәкми. Ул хәтта чүбен утамасаң да үсә, – ди Салихҗан Әхмәтханов.

Быел кабакка бер чиләк суга бер килограмм шикәр комы салып болгатылган су сиптереп тә караган. Серкәләнергә шуның да файдасы булгандыр дип фаразлый Борнак Мичурины. Шуңа күрә башка елларда ике йөк машинасы уңыш бирә торган бакчадан биш йөк машинасы кабак җыеп алганнар булса кирәк. «Уңышны җыеп алгач, кабакның сабагын җыярга кирәкми. Җирдә калсын. Шунда череп бетә ул. Җирне тукландыра. Кабак җирен сабагы-ние белән сукалыйсы да куясы. Элек бакчага гәрчич тә сибә идем. Ул җирне чистарта. Аннары гәрчич кыйммәтләнә башлагач, арыш чәчтем. Аның да файдасы бар», – ди Салихҗан Әхмәтханов.

Оста әретеп ябыштыручы Салихҗан абый бер минут тик утыра торган кеше түгел. Без килгәндә дә су краны ватылган авылдашына ярдәм итеп кайтып килеше иде. Көннәр суыткач, газ мичен кабыза алмаган кешеләр дә Салихҗан абыйга мөрәҗәгать итә икән. Кышын исә уллары Ирек һәм Илдан белән хуҗалык малларына тимер чылбырлар үрә алар. Шуны ашлыкка яки малга алыштыралар. Авылда почта мөдире булып эшләгән хәләл җефете Гөлфирә апа белән 9 сыйныфта укучы кызлары Илсинә дә – хуҗалык эшләрендә Салихҗан абыйның иң төп ярдәмчеләре. Барың бер булып, бергә тырышканда гына тормыш арбасы җиңел тәгәри шул ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

15 октябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан ГАРИФУЛЛИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Ялгыш күчерелгән акчаны куллана аламмы?

Күптән түгел банк картасына шактый гына зур суммада акча килеп төште. Беркайдан бернинди акча аласым юк иде. Ялгыш күчергәннәрдер дип аңладым. Шул көннән бирле бер атна вакыт узды. Минем белән элемтәгә керүче дә, акчаны кире кайтаруымны сораучы да юк. Миңа хәзер ни эшләргә? Ул акчаны тотсам, нәрсә булыр икән?

ВЕНЕРА. Әлмәт

Сорауга юрист Гүзәлия Хафизова җавап бирә:

– Бер счеттан икенчесенә акча күчергәндә реквизитларда хата киткән булса, моның өчен акча күчерүче җавап тотарга тиеш. Монда карта хуҗасының бер гаебе дә юк. Ялгыш күчерелгән акчаны кире кайтарып була. Әмма моның өчен шактый вакыт таләп ителә. Монысы – акча күчерүче колагына әйтелгән сүзләр. Сезнең очракта, әгәр дә сез картагызга ялгыш күчерелгән акчаны туздырырга уйлыйсыз икән – мең кат үкенергә туры киләчәк.

Картагызга ялгыш акча күчергәннәр икән, бу хакта кичекмәстән банкка шалтыратып хәбәр итәргә кирәк. Башкача сездән берни таләп ителми. Бу хәлгә банк үзе ачыклык кертергә тиеш. Әгәр сез шушы көтелмәгән акчаның бер өлешен туздырып өлгергән булсагыз, бу чит акчаны үзләштерү дип саналачак. Банк сездән тотылган акчаны да кайтаруны таләп итәчәк. Каршы килсәгез, сезне судка да бирә алалар. Суд банкка отышлы карар чыгарса, карта хуҗасына карата Җинаять кодексының 159 нчы («Мошенниклык») һәм 160 нчы («Үзләштерү һәм туздыру») маддәләре нигезендә җинаять эше ачылырга мөмкин. Банкка 120000 сум акчалата компенсация түләргә яки ике елга иректән мәхрүм ителергә туры киләчәк.

Әгәр карта хуҗасы көтелмәгән акча килеп төшүе турында банкка хәбәр итмәсә, акчаны кире кайтаруны сорап мөрәҗәгать итүче дә булмаса, шикаять срогы тәмамлануга, ул бу акчаны тота ала. Россия Гражданлык кодексының 196 нчы маддәсе нигезендә моны бу вакыйгадан соң өч ел вакыт үткәч кенә эшләргә мөмкин. Әмма шунысына да әзер торыгыз: сезгә ялгыш акча күчергән кеше еллар үткәч тә пәйда булырга мөмкин. Әгәр ул үзенең җитди сәбәп аркасында акчасын вакытында кайтара алмавын дәлилли алса, сезне җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Түләүдән баш тартырга тиешме?

– Мин моңарчы беркайда да теркәлеп эшләмәдем. Рәсми рәвештә 85 яшьлек әбиебезне тәрбияләгән булып саналдым. Шуның өчен акча түләнде. Почтага эшкә урнашырга җыенам. Хәзер мин бу акчадан баш тартырга тиеш буламмы?

Әлфия САФИНА. Баулы

Татарстан буенча Россия Пенсия фонды матбугат хезмәте:

– Өлкән яшьтәгеләрне тәрбияләгән өчен түләү алган кеше рәсми рәвештә эшкә урнашкан очракта, Пенсия фондына барып, бу акчадан баш тартуы турында гариза язарга тиеш. Моны биш эш көне эчендә эшләргә кирәк.

Кайтаваз

Гриф Хәйруллин: «Мин татар икән, ничек итеп бүтән халык булыйм инде?» (1 октябрь, 2021 ел)

Гриф Хәйруллин – күренекле Казахстан галиме, «Туран» университеты профессоры татар халкының язмышы, тарихы, бүгенгесе, киләчәге турында Фәния Әхмәтҗанова белән күләмле, төпле, җитди әңгәмәсе татар кешесен битараф калдырмый! Төп фикер: күп нәрсә үзебездән тора. Беренче адым: милли белем бирү системасын булдыру. Икенчесе: җанисәптә үзеңне татар дип яздыру. Өченче адым: халык санын арттыру. Дүртенчесе: Татарстанга татарларны туплау. Татар зыялыларын, эшләгән эшләрен телевидениедә ешрак күрсәтү. Бишенчесе: чит төбәкләрдәге татарларга Татарстан белән һәм үзара элемтәләрне ныгыту. Гомумән, татарга уянырга, йокламаска, алга барырга кирәк!

Хәлил ГАЙНЕТДИНОВ

***

Хөрмәтле Фәния Кәбир кызы! Сез гел эзләнүдә. Сокланабыз. Кызыклы, эчтәлекле язмаларыгыз белән сөендереп торыгыз. «Ватаным Татарстан» газетасын бик яратып укыйбыз. Сездәй милләтпәрвәр кешеләр барда үткәнебез дә, хәзергесе дә киләчәк буынга барып җитәр. Рәхмәт сезгә!

***

Милләтпәрвәр каләм иясе Фәния Кәбир кызы! Язмаларыгыз тирән эчтәлекле. Рәхмәт сезгә!

***

Бик көчле язма, мондый тирән фикерле галимнәр күбрәк булсын иде.

***

Бик дөрес фикерләр. Барысы белән дә килешәм! Әмма читтә яшәүче татарлар бездән күпкә «татар» шул. Моның сәбәбе әле дә аңлашылмый...

(Сайтка килгән фикерләр)

Сорау – җавап

ЧҮП КЕНӘ УЛ, ДИМӘ

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең элемтә үзәгенә каты көнкүреш калдыкларына бәйле күп кенә сораулар кабул ителә.

Исегезгә төшерәбез: республикада яшәүчеләргә 2020 елның 1 мартыннан торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә каты көнкүреш калдыклары өчен дә түләү кертелгән счет-квитанцияләр җибәрелеп килә. «Татэнергосбыт»ның, агент буларак, бу түләүне исәпләвен әйтеп үтү мөһим.

Компания белгечләре Татарстанда яшәүчеләрдән иң еш алына торган сорауларга җавап бирә.

– «Каты көнкүреш калдыклары белән эш итү» хезмәтен кем күрсәтә?

– Бу хезмәтне күрсәтә:

◆идарәче компания, торак милекчеләре ширкәте, торак яки торак-төзелеш кооперативы (күпфатирлы йорт белән кем идарә итә – шул);

◆төбәк операторы:

– торак йортлар милекчеләренә;

– гомуми җыелышта төбәк операторы белән турыдан-туры килешү төзү турында карар кабул ителгәндә – күпфатирлы йортта торак милекчеләренә;

– турыдан-туры идарә итү ысулы сайлап алынганда – күпфатирлы йортта торак милекчеләренә.

– Минем чүбем юк (аны үземнең җир кишәрлегенә күмеп куям яки яндырам). Шулай икән, чүп чыгарган өчен мин түләргә тиешме?

– Торак йортлар милекчеләренә каты көнкүреш калдыклары белән эш итү хезмәте күрсәтү буенча килешү төзү мәҗбүри. Калдыкларны бары тик махсус җиһазланган урыннарга гына җыярга мөмкин. Мондый мәйданчыклар әйләнә-тирә мохитне саклау таләпләренә һәм санитария-эпидемиология нормаларына җавап бирергә тиеш. Һавага чыккан төтенне чистарта торган махсус җиһаздан башка гына калдыкларны яндырырга ярамый. Моннан тыш I–IV класс хәвефлелектәге калдыклар белән эш итүгә лицензия таләп ителә. Бу кагыйдәләрне бозган өчен йорт яки җир милекчесе штрафка тартылырга мөмкин.

– Каты көнкүреш калдыклары җыю һәм чыгару буенча ташламалар каралганмы? Бу ташламаларны алу өчен кая мөрәҗәгать итәргә?

– Кешеләрнең төрле категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр бирүдә калдыклар белән эш итү хезмәтенә түләү дә исәпкә алыначак. Компенсация алу өчен яшәү урыны буенча социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Шунысы да бар: чүпне аеруга, аннан хәтәр калдыкларны һәм, алга таба эшкәртү өчен, икенчел чималны аерып алуга төбәк операторлары җавап бирә:

• көнбатыш зона буенча – «ПЖКХ» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (**тел.: 8-843-272-51-33**);

• көнчыгыш зона буенча – «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (**тел.: 8-800-333-09-87**).

Фикер

Татар халкы – бөек халык

Кайбер зыялы миллəттəшлəребезнең, татар милләте бетәчәк, татарның үз дәүләте булмаячак, дигән фикерләре белән һич кенә дә килешмим. Татар теле, милләт, динебез беркайчан да бетмәячәк. Хәзерге вакытта милләттәшләребезнең узаңы үсә, ныгый бара. Замана уңай якка үзгәрер. Россия җитәкчеләренең татар телен, милләтен бетерү хыяллары буш куык кебек калыр. Шуны онытмасак иде. Ул җитәкчеләр мәңгегә килмәгән бит әле... Аллаһка шөкер, мәчетләрдә татар телен өйрәнү дәресләрен оештыру да – күркәм күренеш. Горур булыйк, милләттәшләрем! Өметсезлеккә бирелмик. Килер бер көн, татар халкы һичшиксез үзенең дәүләтен торгызыр. Татар халкы – бөек халык.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ. Казан

Китап итеп чыгарырга кирәк

Татар газеталарының тиражлары кимү борчый мине. Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе менә шул мәсьәләгә игътибар итсен иде. Татар телен урамда кычкырып йөреп кенә саклап калып булмый. Татарча газета-журналларны сакларга, үстерергә кирәк. Без үзебез матбугатны гаиләбез белән укып барабыз. Аннары сезнең газетада бик матур гына «Бу – минем туган авыл!», «Шәфкать» исемле бәйгеләр уздырылды. Шушы бәйгегә килгән язмаларны туплап, брошюра яки китап чыгарсагыз, яхшы булыр иде. Юкса алар югалып бетәчәк бит. Басылып чыга калса, мин үзем шундый ун китап сатып алыр идем.

Шәукәт КАМАЛОВ. Алексеевск районы Кыр Шонталысы авылы

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

11 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Җырлыйк әле!» 6+
05.50, 07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 23.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ» 12+
10.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.50 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 Алтын мирас. «Хәния Фәрхи җырлый» 6+
16.30 «Халкым минем...» 12+
18.00 «Мин» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Семь дней+» 12+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Чёрное озеро» 16+
00.45 «Достояние республик». Док. фильм 12+
01.10 «ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.45, 01.05 «Манзара» 6+
08.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.00, 04.10 «Башваткыч» 12+
11.00, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30, 00.15 «Тамчы-шоу» 6+
12.25, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.15 «Семь дней» 12+
14.30 «Аулак өй» 6+
15.15 «Ач, шигърият, серләреңне» 6+
17.30 «Татарлар» 12+
19.10, 23.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Новости Татарстана» 12+
21.25, 03.25 «Оныта алмыйм» 6+
23.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.20, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «РУССКИЕ ГОРКИ» (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 «Познер» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 21.20 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.35 Футбол. Отборочный матч Чемпионата мира-2022. Словения – Россия. Прямая трансляция из Марибора
23.45 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 11.30, 13.40, 15.45 Новости
06.05, 11.35, 21.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Борьба. Чемпионат мира. Трансляция из Норвегии 0+
09.20, 14.40, 15.50 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ 2» 16+
12.15 Специальный репортаж 12+
12.35, 13.45 «БОЛЬШОЙ БОСС» 16+
16.55 Париматч. Вечер профессионального бокса. Альберт Батыргазиев против Лазе Суата. Бой за титул чемпиона Европы по версии WBO. Прямая трансляция из Уфы
18.55 Хоккей. КХЛ. ЦСКА – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
21.35 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Хорватия – Словакия. Прямая трансляция
00.30 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Словения – Россия 0+
02.25 «Человек из футбола» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Автоспорт. Кубок Чеченской Республики по автомобильным кольцевым гонкам «AKHMAT Race». Трансляция из Грозного 0+
04.30 «Несвободное падение. Олег Коротаев» 12+
05.30 «Ген победы» 12+

НТВ

04.45 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ « (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
21.20 «КРИМИНАЛЬНЫЙ ДОКТОР» (S) 16+
23.55 Детектив «КОНСУЛЬТАНТ. ЛИХИЕ ВРЕМЕНА» (S) 16+
03.35 Их нравы 0+
04.00 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Мёртвая» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.55 «Порча». «Дублёрша» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «ВСЁ РАВНО ТЫ БУДЕШЬ МОЙ» 16+
19.00 «АЛМАЗНАЯ КОРОНА» 16+
23.20 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4» 16+
01.20 «Реальная мистика» 16+
02.20 «Верну любимого» 16+
02.45 «Порча» 16+
03.10 «Знахарка» 16+
03.35 «Понять. Простить» 16+
04.35 «Тест на отцовство» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

04.30 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО» 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20 «ШТРАФНОЙ УДАР» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 18.30 «Специальный репортаж» 12+
13.50, 14.05 «МАРЬИНА РОЩА-2» 12+
14.00 Военные новости
18.50 «Подпольщики». Док. сериал. «Они были первыми» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №74» 12+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Великий комбинатор ГУЛАГа – генерал Нафталий Френкель» 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
01.20 «ЗЕЛЕНЫЙ ОГОНЕК» 6+
02.30 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
04.15 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа». Док. фильм 12+
05.10 «Москва фронту». Док. сериал 16+

12 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.50, 07.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 23.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ» 12+
10.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
11.00 «Туган җир» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.50 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.30 «Халкым минем...» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. – «Салават Юлаев» (Уфа) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Семь дней+». Певец, заслуженный артист РТ Филюз Кагиров 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники» 12+
00.40 «Черное озеро». Крот в банке 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.15, 01.05 «Манзара» 6+
08.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
09.00, 12.00, 15.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.00, 04.10 «Җырлыйк әле!» 6+
11.05, 19.30, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
12.25, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.15 «Ачыктан-ачык» 12+
14.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
14.30 «Аулак өй» 6+
17.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Ак барс» (Казан). Трансляция – Уфадан 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Новости Татарстана» 12+
21.52, 03.25 «Оныта алмыйм» 6+
23.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «РУССКИЕ ГОРКИ» (S) 16+
22.35 «Док-ток» 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 К 95-летию Никиты Симоняна. Премьера. «ЕГО ВЕЛИЧЕСТВО ФУТБОЛ» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» Ток-шоу 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ» 12+
23.40 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 11.30, 13.40, 15.45, 21.00 Новости
06.05, 18.00, 21.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.15 Специальный репортаж 12+
09.20, 14.40, 15.50 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ 2» 16+
11.35 «МатчБол»
12.35, 13.45 «ДРАКОНЫ НАВСЕГДА» 16+
16.55 Смешанные единоборства. Fight Nights & GFC. Владимир Минеев против Даурена Ермекова. Трансляция из Москвы 16+
17.25 Смешанные единоборства. АСА. Магомед Исмаилов против Ивана Штыркова. Трансляция из Москвы 16+
18.25 Футбол. Чемпионат Европы-2023. Молодёжные сборные. Отборочный турнир. Литва – Россия. Прямая трансляция
20.30 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Обзор 0+
21.35 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Англия – Венгрия. Прямая трансляция
00.30 Тотальный футбол 12+
01.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. УНИКС (Россия) – «Бавария» (Германия) 0+
01.45 Баскетбол. Евролига. Мужчины. ЦСКА (Россия) – «Зенит» (Россия) 0+
02.30 Хоккей. НХЛ. «Тампа-Бэй Лайтнинг» – «Питтсбург Пингвинз». Прямая трансляция

НТВ

04.45 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
21.20 Премьера. «КРИМИНАЛЬНЫЙ ДОКТОР» (S) 16+
23.55 Детектив «КОНСУЛЬТАНТ. ЛИХИЕ ВРЕМЕНА» (S) 16+
03.35 Их нравы 0+
03.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика». «Баловница судьбы» 16+
07.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Замри-умри» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ЧУЖАЯ СЕМЬЯ» 16+
19.00 «ВОСПИТАНИЕ ЧУВСТВ» 16+
22.55 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 19-я и 20-я серии 16+
01.00 «Реальная мистика» 16+
02.00 «Верну любимого» 16+
02.30 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20, 13.25, 18.30 «Специальный репортаж» 12+
09.40 «ШАГ НАВСТРЕЧУ. НЕСКОЛЬКО ИСТОРИЙ ВЕСЕЛЫХ И ГРУСТНЫХ...» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.50, 14.05 «МАРЬИНА РОЩА-2» 12+
14.00 Военные новости
18.50 «Подпольщики». Док. сериал. «Маршрут спасения» 16+
19.40 «Легенды армии». Александр Голованов 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ШЕСТОЙ» 12+
01.20 «ШТРАФНОЙ УДАР»
02.50 «ДЖОКЕРЪ» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Әхмәтҗанов** Рөстәм Шәрәфиәхмәт улы; «АгроЛак» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы **Гыйлаҗев** Илсур Миңлеәхмәт улы; Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгы **Зыятдинов** Радик Рәгыйп улы; «НУР» АГРОФИРМАСЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Нургалиев** Радик Галимҗан улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«АЗНАКАЙ» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы **Шәмсемөхәмммәтов** Хәлил Хаҗимөгаммәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«АксуАгро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлек азыгы әзерләү операторы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Зарипова** Флера Харис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Кукмара районының фермер һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе **Бариев** Таһир Гаптелхәбир улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар буенча консультанты **Вәлиева** Лүзия Мөнир кызына; «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары (Татарстан Республикасының Зеленодольск районы) **Ганиев** Руслан Илшат улына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе дәвалау-профилактика чаралары бүлеге башлыгы **Латыйпов** Солтан Сәлим улына; «Садыйков Равил Әксән улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Баулы районы) **Садыйков** Равил Әксән улына; «ҖӘЛИЛ» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең агрономия хезмәте әйдәүче агрономы (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Хәертдинов** Таһир Зәйнетдин улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының азык-төлек базарын үстерү бүлеге өлкән белгече **Хөснетдинова** Суфия Габделхәй кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Әхәтов** Булат Хираҗетдин улына; «Тукай» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Мияссәров** Инсаф Юрат улына; «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Сабиров** Рәсим Асыл улына; «Алан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Шәйхетдинов** Зөфәр Фәрит улына; «Колос» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте экскаватор машинисты (Татарстан Республикасының Саба районы) **Шәрафетдинов** Рәфил Рафаил улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЕРЫК АВЫЗ

Очкычта радио аша хәбәр яңгырый:

– Хөрмәтле пассажирлар! Сезнең арада табиблар бармы?

Табиб табыла һәм ул очучылар кабинасына кереп китә. Бераздан микрофоннан яңадан тавыш ишетелә:

– Хөрмәтле пассажирлар! Сезнең арада пилотлар юкмы?

***

Россиядә экологик яктан чиста беренче машина ясаганнар. Табигатькә зыян салмасын өчен аны бөтенләй йөрми торган итеп эшләгәннәр.

***

Чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм! Ходай сезгә бәхет, мәхәббәт, сәламәтлек, чибәрлек, байлык, фатир, яхшы эш урыны, тугры дуслар һәм акыл насыйп итсен! Ә калганы сезнең үзегездә дә бар инде.

***

Бишенче сыйныфка кадәр Равил урысча да начар белде, йөгергәндә дә хәле бетеп егыла иде. Әмма бер вакытны дәресләрдән соң ялгышып сыйныфка килеп кергәннән соң, ул мәктәпне тәмамлаганчы урыс теле һәм физкультура дәресләреннән һәрвакыт «бишле» генә ала башлады.

***

Хатын-кызның дөньяда иң курыккан нәрсәсе – юанаю. Ә инде юан хатын-кызлар дөньяда бернидән дә, беркемнән дә курыкмыйлар.

ИНСУЛЬТ: ҺӘР СЕКУНД САНАУЛЫ

Һәр 1,5 минут саен Россиядә инсульттан бер кеше үлә. Белгечләр, киләчәктә бу ешлык тагын да кыскарырга мөмкин, дип чаң суга. Ник дигәндә, соңгы елларда инсульт яшьләр арасында ешрак күзәтелә башлаган. Иң куркыныч заман афәтләренең берсе саналган инсульт турында без нәрсә белеп торырга тиеш?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА шул сорауларга ачыклык кертте.

:: Диләрә Рәхимовна, соңга елларда инсульт ни сәбәпле яшәрә?

– Инсульт, дөрестән дә, елдан-ел яшәрә. Моңа нигездә вакытында ачыкланмаган артериаль гипертония сәбәпче. Күпләр үзенең югары кан басымы белән йөрүен белмичә дә яши. Табибка күренергә килгәч, тонометрдагы югары күрсәткечне күреп шаккаталар. Югары кан басымыннан интегү нәселдән дә килергә мөмкин. Чамадан тыш калорияле, трансмайлар кушып әзерләнгән ризык ашау, фаст-фуд белән мавыгу да инсульт килеп чыгу куркынычын арттыра. Ник дигәндә, мондый туклану рәвешенә өстенлек биргән кешенең кан тамырларына бик зур зыян килә. Соңгы елларда кешеләр азрак хәрәкәтләнә башлады. Бу шулай ук инсультның елдан-ел яшәрүенә китерде. Стресслар да эзсез узмый.

:: Инсульт куркынычы аеруча кемнәргә яный?

– Ишемия, гипертония кебек йөрәк-кан тамыры авырулары булган, симезлектән интеккән кешеләр – риск төркемендә. Атеросклероз диагнозы куелган кешеләргә дә сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Бу төркемгә, нигездә, тәмәке тартучылар керә.

:: Инсультның нинди төрләре бар?

– Ишемия төрендәге инсульт кан тамырларын кан белән тәэмин итүнең бозылуы аркасында килеп чыга. Аның билгеләре акрынлап беленә башлый. Кешенең күзе начар күрә башлый, кул-аяклары ойый, башы әйләнә, башы авырта. Ишемик инсульт йоклаганда яки иртүк «бәрә». Бу очракта гәүдәнең билгеле бер өлеше зарлана. Геморрагик инсультка исә баш мие тукымасына кан саву сәбәпче була. Аның билгеләре кисәк кенә сиздерә башлый. Кешенең бик каты башы авырта, күңеле болгана, коса, буыла башлый, комага китәргә мөмкин. Моннан тыш инсультның катнаш һәм микроинсульт дигән төрләре дә була. Соңгылары җиңелчә генә үтеп китә.

:: Коронавирус белән авырган кешеләргә дә инсульт куркынычы яный, диләр...

– Коронавирус инсульт китереп чыгара ала. Ник дигәндә, бу очракта канның оешу сәләте бозыла. Шул рәвешле алар тромблар пәйда булуга сәбәпче була. Тромб исә инсульт китереп чыгара. Болар бар да үзара бәйләнгән.

:: Инсульт вакытында нинди билгеләр күзәтелә?

– Инсульт вакытында күзәтелгән төп билгеләрне һәркем белеп торырга тиеш. Иң элек инсульт вакытында кул-аяклар көчсезләнә. Моны тикшереп карау өчен кешедән ике бармагыгызны кысуын сорагыз. Башта бер кулын, аннары икенчесен тикшерегез. Ике кулны да бер төрле итеп кысмаса, шикләнергә җирлек бар. Авырудан ике кулын өскә күтәрүен сорарга да онытмагыз. Параличланган кул шундук килеп төшәчәк. Аякларны да шул рәвешле тикшереп карарга кирәк. Аякларын өскә күтәртеп, 90 градуска бөкләп, шул халәттә бернічә минут торуын сорагыз. Аякларын тотып тора алмаса, бу шулай ук инсульт билгесе булачак. Инсульт булган кешенең йөзе бер якка кыйшаерга да мөмкин. Ул бик нык башы әйләнүдән дә зарланачак.

«Ашыгыч ярдәм» машинасы килгәнче инсульт билгеләре күзәтелгән кешегә ничек ярдәм итәргә?

➤«Ашыгыч ярдәм» машинасы килгәнче авыруны иң элек тынычландырырга кирәк. Дулкынланганда аның авыруы тагын да көчәя, кан басымы күтәрелә.

➤Авыруны яткырыгыз, башын мендәр белән бераз гына күтәрегез. Аңында булмаса, башын янга борыгыз. Бу, ул аңына килеп, коса калса, тончыкмасын өчен эшләнә.

➤Кысып торган киемнәрен чишеп җибәрегез. Тәрәзәне ачып бүлмәне җилләтеп алыгыз. Авыру һавага кытлык кичерергә тиеш түгел!

➤Кан басымы югары булган кешегә кан басымын төшерә торган дару бирсәгез була. Әмма табиблар килгәнче башка төрле дару эчерергә киңәш итмәс идем. Бу авыруның хәлен тагын да катлауландырырга мөмкин.

➤Инсульт билгеләре булган кешене алты сәгать эчендә хастаханәгә илтеп җиткерергә кирәк. Бу очракта һәр секунд санаулы!

Укучы соравы

НИНДИ ТАШЛАМАЛАР КАРАЛГАН?

Ике ай элек инфаркт кичердем. Миңа бирәр нинди ташлама каралган микән?

Фәрит ВӘЛИЕВ. Арча

Сорауга Росздравнадзор каршындагы авыру хокукларын яклау буенча иҗтимагый оешмалар советы әгъзасы Алексей СТАРЧЕНКО җавап бирә:

– Хөкүмәтнең 890 нчы номерлы карары нигезендә инфаркт кичергән кешегә беренче алты айда барлык дарулар да бушлай бирелергә тиеш. Кеше савыкса, киләчәктә ул үз хисабына дәваланырга тиеш булачак. Авыруның сәламәтлеген яхшыртып булмаган очракта аны инвалидлык буенча төркем бирү өчен медицина-социаль тикшерену узарга җибәрәләр. Группа алган очракта авыру даруларны алга таба да бушлай яки 50 процент ташлама белән алачак. Сүз уңаеннан: инсульт ташламалы дару алырга мөмкинлек бирүче чирләр исемлегенә кертелмәгән. Әлеге мөмкинлектән авыруган вакытта «льготник» статусында булган (инвалид, сугыш ветераны, пенсионер һ.б.) кешеләр генә файдалана ала.

ОРГАНИЗМГА НИ ҖИТМИ?

Кеше организмы үзенә нәрсә җитмәве хакында теге яки бу ризыкны сорап, сигнал бирә.

1 Гел шоколад ашыйсы килсә, организмга магний җитми дигән сүз. Ул чикләвек, көнбагыш орлыгы, җиләк-җимеш, кузаклыларда күп.

2 Майлы ризыкларга тартылсагыз, организмга кальций җитми. Ул брокколи, кузаклылар, сыр, көнҗеттә күп.

3 Гел сыр ашыйсы килгән кешегә, организмны кальций гына түгел, фосфор белән дә баету ягын карарга кирәк. Алар брокколи, сөт, эремчектә күп.

4 Ысланган ризыкларга тартылсагыз, организмга май кислотасы җитми дигән сүз. Ул авокадо, кызыл балык, зәйтүндә күп.

5 Организмыгыз гел әче ризыкларга тартылса, С витамины җитми. Ул лимон, мүк җиләге, киви, бакча җиләге, гөлҗимештә күп.

6 Баллы ризыкларга бәйлелек глюкоза җитешмәүдән. Глюкозага хөрмә, бал, йөзем, кукуруз бай.

Киңәш-табыш

Кан басымын төшерә

С витамины чыганагы саналган гөлҗимеш – бик күп төрле авырулардан дәва. Бигрәк тә югары кан басымыннан интеккән кешеләр өчен шифасы зур аның. Файдалы төнәтмәне ясау өчен 1 аш кашыгы гөлҗимешкә 3 стакан су салып, ике тапкыр кайнатып чыгарыгыз да 3 сәгать томалап тотыгыз. Шуны көн дәвамында җылытып эчегез. Башка бернинди сыеклык эчәргә һәм ит ашарга ярамый! Әлеге төнәтмә ярдәмендә ай ярым дәваланырга киңәш ителә. Әмма шунысын да истән чыгармагыз: гастрит, язва вакытында гөлҗимеш төнәтмәсе эчәргә ярамый!

Зәйтүн мае яшәртә

Зәйтүн мае йөрәк-кан тамыры авыруларын кисәтә, кан әйләнешен яхшырта. Кандагы холестерин күләмен киметүе, ашказаны яман шешеннән саклавы белән дә игътибарга лаек ул. Зәйтүн мае составына керүче микроэлементлар һәм витаминнар кеше организмына уңай йогынты ясый, бавыр, эчәклек, шулай ук ашказаны асты бизе эшен җайга сала. Шуңа күрә белгечләр зәйтүн маен гастрит һәм панкреатит вакытында кулланырга киңәш итә. Анда А, Е, Б һәм К витаминнары бар. Зәйтүн мае тән тиресе өчен дә бик файдалы. Ул аллергия бирми, тиреңе йомшарта һәм ялкынсынуга каршы чара булып тора. Бит тиресен яшәртәм дигән кешегә түбәндәге битлекне ясап карарга киңәш ителә. 2 аш кашыгы зәйтүн маена 1 йомырка сарысы кушып, яхшылап болгатыгыз. Шуны биткә сөртеп, 20–25 минут тотыгыз һәм салкынча су белән юып төшерегез.

Баш авыртып йөдәтсә...

Гриппан коткаручы иң нәтиҗәле чараларның берсе саналган лимон баш авыртканда да ярдәмгә килә. Моның өчен ак элпәсеннән чистартылган лимон кабыгын юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотарга кирәк. Озаклаьый лимон кызарып чыгар, ә баш авыртуы бетәр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Бакчачы почмагы

ТЕПЛИЦАНЫ КӨЗЕН ӘЗЕРЛИЛӘР

Чананы – яздан, ә менә теплицаны көздән әзерләп куйсаң яхшы. Салкыннар башланганчы бер эшегезне тәмамлап кую өчен хәзер менә дигән вакыт.

1. Теплицадагы корыган үләннәрне җыеп алырга. Туфракның 7 сантиметр чамасы өске катламын җыеп ташларга. Бу бик сәер тоелыр, әмма ул сезгә чүп үлән орлыкларыннан һәм корткыч бөҗәкләрдән котылырга ярдәм итәчәк.

2. Туфракны тирес, торф яки көл сибеп яхшылап казыгыз. Аннары түтәл өстенә салам түшәп чыгыгыз.

3. Кышын теплицага кар кертегез. Бу, бердән, туфракны дым белән туендыра, икенчедән, андагы туфракның кышын артык туңмавы өчен кирәк. Чөнки каты туңмаган туфрак язын тизрәк өлгерәчәк.

4. Корыган үләннәрне һәм туфракның өске катламын алу ул әле корткычлардан котылдым дигән сүз түгел. Шуңа күрә корткыч бөҗәкләргә каршы кулланыла торган препарат сибеп калдырсагыз да яхшы булыр.

ИСЕНДӘ ТОТ!

✸ Теплицадагы бөтен тузан һәм пычраклардан арынызыз.

✸ Каркасының ватылган урыннары булса, төзәтегез. Металл детальләрен коррозиядән саклагыч яки буяу белән капларга кирәк.

✸ Тәрәзә, форточка, ишекләре барысы да төзекме? Әгәр төзәтәсе урыннар булса, вакытында эшен бетереп куегыз.

Остаханә

УҢЫШ БӘЙРӘМЕНӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

Тиздән балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә Уңыш бәйрәмнәре гөрләячәк. Ә сез әзерме соң әле? Әзер булмасагыз, менә бу бакча нигъмәтләреннән ясалган эшләнмәләр сезгә ярдәмгә килер. Мондый мультфильм геройларын балалар да бик яратып ясаячак.

Йорт-җир

Чыгымнарсыз үзгәртәбез

Кайчак тормышыбызга гына түгел, ә яшәгән йорт яки фатирыбызга да үзгәрешләр кертәсе килеп куя. Ел саен ремонт ясап та булмый. Ә менә бертөрлелектән туйганда күңел тынычлыгы бирерлек нинди үзгәрешләр кертергә мөмкин соң? Монда сезгә декоратор Ирина Лазько киңәшләре ярдәмгә килер.

Җыештыр. Бүлмәләрегезне кирәксез әйберләрдән арындырыгыз. Кирәкмәгән әйберләрегезне ташларга, бирергә, сатарга мөмкин. Кулланмаган әйберләрегезне кызганмагыз. Әллә ничә ел торган ватык телевизорны хәзер генә төзәтеп тормаячаксыз бит инде. Чыгарылыш кичәсендә кигән күлмәгегезне дә киммәячәксез, билгеле. Калган кирәкле әйберләрне шкаф, комод, киштәләргә урнаштырыгыз. Шулай ук әйберләр салып кую өчен төрле зурлыктагы тартма, матур кәрҗиннәр куллану да өегезне ямьләп, кәефегезне күтәреп җибәрер.

Алыштыр һәм яктырт. Әллә ничә ел торган люстраны яңасына алыштырсагыз да, бүлмәгез үзгәреп киткәндәй тоелыр. Бүлмәләргә, гадәттә, түшәм уртасына бер генә люстра куела. Уңай, рәхәт мохит тудыру өчен карават янына торшер яки тәрәзә пәрдәләренә гирлянда эләргә мөмкин. Әйе, гирляндаы Яңа елда гына куярга димәгән. Шулай ук абажур, лампочканы яктырак алыштыру да күңелегезне күтәреп җибәрер. Иң мөһиме – якты булсын.

Яшер. Идәндә аунап яткан интернет кабеле, техника чыбыклары өйдә бик үк тәртип булмаган төсмер бирә. Шуңа күрә аларны яшерергә тырышыгыз. Яшерергә мөмкин булмаган чыбыкларны дивар төсенә буярга һәм кызыклы орнаментлар белән бизәп яшерергә мөмкин.

Тәмле булсын!

ФАЙДАЛЫ ЯШЕЛ АДЖИКА

Әлеге тәмләткечне ит, бәрәңге белән табынга бирергә, кәтлит һәм пилмән фаршына кушарга, карп балыгының эченә сөртеп пешерергә мөмкин. Аны ясауга ук кулланырга да мөмкин. Суыткычта сакларга киңәш ителә.

Кирәк: 3–4 баш сарымсак, 3–4 суган, 3–4 яшел татлы борыч, 3 данә әче борыч, петрушка, укроп бәйләме.

Барлык яшелчә һәм тәмләткечләрне иттарткычтан чыгарырга. 1 аш кашыгы тоз, 3 аш кашыгы шикәр комы, 0,5–1 чәй кашыгы уксус һәм 1 стакан үсемлек мае салырга һәм яхшылап болгатырга. Яшел аджиканы банкаларга салып, суыткычка куярга. Әлеге тәмләткеч тәмле генә түгел, бик файдалы да. Тик ашказаны-эчәк авырулары белән интегүчеләргә сак булырга киңәш ителә.

КҮРКӘ ИТЕННӘН АЗУ

Күркә итеннән яшелчәле азу кичке ашка яки бәйрәм өстәленә менә дигән тәмле ризык.

Кирәк: 0,5 кг күркәнең түш ите, 1 тозлы кыяр, 1 помидор, 5 бәрәңге, 1 тырнак сарымсак, 1 суган.

Туралган күркә итен ярымбөҗралап туралган суган, саламлап туралган тозлы кыяр салып табада кыздырырга. Помидор белән сарымсакны ваклап турап табага салырга һәм бер стакан су салып әзер булганчы пешерергә. Аннары өстенә саламлап туралган кыздырган бәрәңгене өстәп болгаткач, 10 минут чамасы пешерергә. Өстенә яшел тәмләткечләр салып табынга бирергә.

Укучы киңәше

Казның сере – түшендә

Тиздән каз өмәләре башлана. Сатарга дип үстерүчеләр казларын иртәрәк суеп урнаштырса, үзләре өчен дип асраучылар әле түң төшкәнне көтә. Мамадыш районында яшәүче **Зөлфия ДӘҮЛИЕВА** да каз өмәсен бик иртә уздыру яклы түгел. Чөнки кар төшкәч чалынган казның ите тәмлерәк, ди ул. Ул шулай ук каз ашату буенча киңәшләрен дә бирде.

– Казның түшкәсе үссен өчен аңа җылы җим кирәк. Моның өчен кабак, бәрәңге, чөгендерне, булса, бакчадагы коелган алмаларны кушып, бераз бодай салып пешереп ашатсаң яхшы. Ә суыткач, җим ката башлаганнан соң, пешерми генә бодай һәм арпа ашатыла. Кайбер кеше борчак та бирә. Ә суяр алдыннан борчак ашатканда казның ите бик тәмле булмый.

Казның чалырга әзерме-юкмы икәнлеген түшеннән белеп була. Җитлеккән, әзер казның түше тотып караганда шадра булып тора.

#ҺӘР ТАПКАН НАСЫЙП ТҮГЕЛ

Насыйп әйбер теш ярып керер, ди халык. Әмма юлыңа чыккан, юлда табылган һәр әйберне насыйп әйбергә генә кайтарып калдыру дөресме икән? Мисал өчен, юлда очраган нинди дер әйбер, шул ук акча, кемнеңдер малы, кадерле әйберсе булырга мөмкин бит. Нәрсәдер тапкан очракта нишләргә? Табылдыкны кесәңә салып кую гөнаһмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бу сораулар белән Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт БИКБАЕВка мөрәҗәгать иттек.

:: Равил хәзрәт, юлда тапкан акчаны ни эшләтергә кирәк? Аны үзеңә алсаң, гөнаһ саналамы?

– Әгәр тапкан акча аз күләмле, әйтик, 10–20 сум тирәсе генә булса, ул вакытта аны алырга ярый. Ә инде тапкан акча 50–100 сумнан башланса, ул вакытта инде аны иясенә тапшырырга кирәк. Табылдыкның хуҗасын эзләүнең бик күп ысуллары бар хәзер. Әйтик, аны шул ук Ватсап төркемнәренә игълан таратып таратып барга мөмкин. Авыл җирендә халык күп йөри торган иң төп урын – кибет янына фәлән әйбер табылу турында белдерү элеп куеп та була. Әгәр хуҗасын таба алмасаң, тапкан әйберне аның исеменнән сәдака итеп бирәсең.

:: Юлда акча тапкан кеше үзе дә фәкыйрь булса, бу очракта ни эшләргә?

– Бу очракта аңа тапкан акчаны, әйберне үзенә калдырса да рөхсәт ителә. Андый чакта инде аның төгәл ничә сум акча табуы мөһим түгел.

:: Ислам дине табылдыкка нинди мөнәсәбәттә?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссалам бер хәдисендә: «Сыер, дөя кебек югалган зур хайваннарга кагылмагыз. Алар бүрегә дә каршы тора алалар. Ә менә бүре ашый ала торган сарык кебек хайваннарны алыгыз, иясен эзләгез. Әгәр ул кешенең игътибарын җәлеп итми торган таяк, бау шикелле генә вак әйбер булса, аны үзегезгә алып куллансагыз да була», – дигән. Әйтик, авылда сыер табылып, аны кешеләр урлап, суеп урнаштыру куркынычы юк икән, аңа тияргә ярамый. Аның хуҗасы барыбер табылачак.

:: Авылда: «Абзарга каяндыр бер сарык килеп керде. Куып та чыгарып карадык, эзләп-эзләп хуҗасы да табылмады. Шулай бездә калды инде», – дип сөйләгән кешеләр бар. Бу очракта үз аягы белән килеп кергән малны үзеңә калдыру гөнаһ саналамы?

– Бер елдан соң да иясе табылмаса, бу мал синеке булып санала. Игълан кылганнан соң, фәкыйрь кеше аны үзенә калдыра ала. Башка очракта аны хәер итеп мохтаҗларга бирергә тиеш була.

:: Шундый очракны күз алдына китерик: кеше юлдан акча, кыйммәтле әйбер, йә булмаса, мал тапкан, ди. Бер ел эзләп тә, хуҗасын тапмаганнан соң тапкан әйберне тотып, урнаштырып бетерә ул. Шуннан 2–3 елдан тегә табылдыкның хуҗасы пәйда булса, бу очракта ни эшләргә?

– Әгәр әйбернең иясе табылса, тапкан кеше аңа иң элек: «Мин сезне бер ел эзләдем. Таба алмадым. Шуңа аны сезнең исемнән сәдака итеп бирдем», – дип хәлне аңлатып бирергә тиеш. Табылдыкның хуҗасы моңа риза булмыйча, тапкан әйберне кире кайтарып бирергә кушса, ул инде аны тулысынча кайтарырга тиеш була. Малны, әйтик, шул ук тапкан сарыкны кире кайтарганчы, озак елдан соң табылган хуҗа кеше тапкан кешегә иң элек бу малга ашаткан азык өчен компенсация түләргә бурычлы. Әйтик, шушы вакыт эчендә ул малга ун мең сумлык азык ашаткан булса, башта теге кешедән шуның өчен акча ала, аннары гына малны кире кайтарырга тиеш.

:: Тапкан әйбергә кагылмыйча, аны күрмәмешкә салышып китү дөресме?

– Табылган әйберне алыргамы-юкмы, дигән мәсьәләдә галимнәрнең фикере икегә бүленә. Аларның күпчелеге болай ди: «Шушы әйбернең иясе табылу ихтималы зур булса, табылдыкка кагылмавың яхшырак. Бу очракта ул үз өстенә өстәмә йөкләмә алмый. Әгәр үзенең бер ел буе шушы табылган әйбернең хуҗасын эзләп йөри алуына ышанса, намуслы кеше булса, аны алса ярый. Ә инде үзенә файда эзләүче кешенең табылган әйбергә бөтенләй кагылмавы хәерле».

КАДАКНЫ КАКМАВЫҢ ХӘЕРЛЕ

Яшәгән ди, булган ди бик дуамал холыклы, тиз кызып китүчән бер егет. Көннәрдән бер көнне моңа әтисе бер капчык кадак биргән. Ачуы чыккан саен шуннан бер кадак алып, коймага кагарга кушкан.

Беренче көнне үк койма дистәләгән кадак белән тулган. Бер атнадан инде андагы кадаклар саны кими төшкән. Егет ачу-ярсуын тыярга өйрәнгән. Ни гаҗәп, тора-бара коймадагы кадаклар саны көн саен кими башлаган. Егет кадак кагуга караганда үз-үзеңне кулда тоту җиңелрәк икәнлекне аңлаган. Көннәрдән бер көнне ул коймага бер кадак та какмый башлаган. Шуннан әтисе аңа үз-үзен кулда тотып калган саен, киресенчә, коймадан берешәр кадак суырып алырга кушкан. Егет шулай эшләгән. Берзаман коймада бер кадак та калмаган. Шуннан әти кеше коймa янына килгән дә болай дигән:

– Койманы кадаклардан чистартып бетерүең бик яхшы булган, улым. Ләкин, күрәсеңме, анда күпме тирән кадак эзе калган. Ул инде беркайчан да элеккеге кебек тишек-тошыксыз, шома булмаячак. Кешегә начар сүз әйткәч, каты бәрелгәч тә әнә шундый тирән яралар кала. Аннан соң күпме генә гафу үтенсәң дә, авыр сүз салган шушы яраларны ямый алмаячаксың. Шуңа күрә тормышта ничек кенә ярсысаң да, үзеңне кулда тотарга, сүзеңне үлчәп сөйләргә кирәк!

pixabay.com

Сорау – җавап

Гөнаһ чынлап та кимиме?

Үзебез турында гайбәт сөйләүләрен ишеткәч: «Сөйләсеннәр, гөнаһларым кимер», – дибез. Андый чакта гөнаһлар, дөрестән дә, кимиме? Кайдан чыккан сүз икән бу?

ӘЛФИЯ апагыз. Әгерҗе

Сорауга «Шамил» мәчете имам-хатыйбы Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН җавап бирә:

– Мөхәммәд пәйгамбәрнең бу уңайдан әйткән сүзләре бар. Бер хәдистә ул: «Кыямәт көнендә гайбәт сөйләгән кешене хисап өчен Аллаһының каршына китерерләр. Ул тау кадәр изгелекләре – тоткан уразалары, укыган намазлары, кылган хаҗлары, биргән хәерләре белән килер. Шуннан соң бу кешенең кылган гамәлләренең әҗер-савапларын гайбәте сөйләнгән кешеләргә таратырлар», – дигән ул.

АВЫРУ КЕШЕНЕҢ СӘЛАМӘТЛӘНҮЕН СОРАП УКЫЙ ТОРГАН ДОГА

Гайшә радыяллаһу ганһә Расүлебезнең үз гаилә әһелләренең хәлләрен белергә килгәч, кулын аларның тәненә тидереп, мондый дога укуын риваять иткән: **«Аллаһүммә Раббин-нәәси, әз һәбил-бәәси, ишфи әнтәш-шәәфии ләә шифә-ә илләә шифәәүукә, шифә-ән ләә йүгаадиру сәкамән».** **Тәрҗемәсе:** «Кешеләрнең Раббысы Аллаһым! Бу авыртуны бетер. Син – шифа Бирүче. Синең шифаңнан башка шифа юк. Бу авырту юкка чыгарлык итеп дәвала» (Имам Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан), дип яза «Дин вә мәгыйшәт».

Бер аять

«Әй мөэминнәр! Яхшы эшләрдә, изге гамәлләрдә, гөнаһлардан һәм золым эшләреннән саклануда ярдәмләшегез! Әмма гөнаһлы эшләрдә һәм дошманлашуда һич тә ярдәмләшмәгез! Аллаһыдан куркыгыз, аның вәгазьләрен, хөкемнәрен игътибарсыз калдырудан сакланыгыз! Дөреслектә Аллаһ сакланмаучылардан каты гәзаб белән үч алучыдыр». («Әл-Мәидә» сүрәсе, 2 аять).

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА:

«ГАИЛӘДӘ БӨТЕНЛӘЙ БАШКА МИН»

Кайчандыр аны кабул итмиләр иде, хәзер, киресенчә, аңа охшарга тырышалар. Рәхмәтен дә, тәнкыйтен дә еш ишетергә туры килә аңа. Эшләмәгән кешене генә күрмиләр, ә тик тормаска күнеккән Татарстанның атказанган артисты Гөлназ СӘФӘРОВАның һәр адымы күз уңында. Без аның белән юбилей концерты, уңыш серләре, хатын-кыз бәхете һәм эстрада хәлләре турында сөйләштек.

:: Гөлназ Сәфәрова – кем ул бүген?

– Тормышта үз позициясен, үз урынын тапкан кеше. Быел минем юбилей, һәм мин теләгән әйберемә ирешеп, үз урынымны булдыра алдым. Бу – сәхнә генә түгел. «Үз урыным» дигәндә мин күңелемә ятышлы эштә эшләвемне дә, үз гаиләмне төзүемне дә, әни һәм кыз булуымны да кертәм – бүгенге образым менә шулардан җыелды.

:: Кечкенә яки үсмер чакта, менә шушы яшемдә шундый уңышларга ирешәчәкмен, дип уйлый идегезме?

– Алдан ук әйтәм: бу минем хыялым түгел иде. Кайчан да булса иң шәп алып баручы булачакмын, танылачакмын, сәхнәдән төшмәячәкмен, дип уйланып, хыялланып утырганым булмады. Бу – эш, минем һөнәрем, һәм мин аңа тыныч карыйм. «Карагыз, мин менә моңа ирештем», – дип тә йөргәнем юк.

Мәктәптә укыганда алдыма шундый максат куйган идем: тормышта дәрәҗәле, тотрыклы позициямне булдырачакмын. Сәхнәдәме ул, юриспруденциядәме, медицина өлкәсендәме – мөһим түгел. Иң мөһиме – үз урыныңны табу, шәхес буларак формалашу, профессионал булу.

:: Танылган журналист һәм укытучы баласы булу җаваплылыгы белән бәйлеме бу, әллә үзегезгә нидер раслыйсыгыз килдеме?

– Үземә. Мин һәрвакыт алдыма билгеле бер планка куя идем. Аңа ирешкәч, тагын да югарыракны. Кеше өчен эшләгәнем булмады. Билгеле, әти-әнинең дә: «Син моны булдыра алмыйсыңмы әллә?» – дигән чаклары шактый булды. Мәсәлән, бу концерт күбрәк әни теләге белән оештырылды. «Үз эшеңә нәтиҗә ясый белергә кирәк», – диде ул миңа. Сүзен тыңладым, әлбәттә. Ләкин күп очракта «кирәк» һәм «тиеш»не үземә үзем әйтә идем. Мәктәптә «бишле» билгеләренә генә укырга кирәк – укыдым, университетны яхшы тәмамларга тиешмен – тәмамладым. Болар минем өчен мөһим иде. «Синдром отличницы» дип әйтәләр бит әле – менә шул булгандыр инде миндә дә.

Бу бит хәзер дә үзгәрми. Көненә икешәр чара алам, тегендә чабам, монда барам. «Нишләп үз өстеңә шулкадәр күп аласың?» – дип еш сорыйлар. Кайвакыт үзем дә, чыннан да, авыр бит бу, дип уйлап куям. Тик тормыш рәвешенә әйләнеп беткәч, киресенчә, шушы максатлардан, үземне һәрвакыт стресста тотудан башка яшәү кыенрак икән ул. Авырлыкларны кичеп чыгу ошый миңа. Табигатем, холкым шундый, күрәсең. Нәтиҗәсен күргәч, шундый рәхәт бит.

:: Сез – лидер. Бу сыйфатның ирегезгә дә хас булуын әйткән идегез. Тәлинкәләр дә ваткалагансыз. Хәзер ничек? Җәмгыятьтә дәрәҗә арткан саен, гаиләдә юл кую авыррак түгелме?

– Юк, хәзер бар да киресенчә. 18 яшьтә үзеңне танк дип уйлыйсың. Әти-әнигә әйткәнем булды: ирем белән аерыласым килә икән, уйлап та тормыйм, имеш. Үзем генә булдыра алам, янәсе. Хәзер бит инде башка акыл да керә башлады, Ленардан, гаиләмнән башка күп нәрсәне булдыра алмавымны бик яхшы аңлыйм. Ленар – миңа да, безнең гаиләбезгә дә зур терәк. Минемчә, хатын-кыз менә шулай ир-ат артында булырга тиештер дә инде. Билгеле, салмыш ирләрнеке түгел, ә үз дәрәҗәсен раслый һәм аклый алган кешенең генә җилкәсе саклый ала.

:: «Хатын-кызның көче – гаиләдә», – дигәнегез бар. Элегрәк, өйдә вакытны аз үткәрәм, дип, үзегезне бик тирги идегез, ахры. Хәзер бераз үзгәрдегезме?

– Әйе, хәзер гаиләм янында булырга мөмкинлек табам. Элегрәк үз исемем өстендә эшләсәм, бүген вакытымны күбрәк якыннарыма багышларга тырышам. Кайбер чаралардан баш тартам, чит шәһәрләргә бик йөрмим. Приоритетларым үзгәрде. Әби әйтмешли, өйдә һәрвакыт яңа пешкән ризык исе һәм чисталык булырга тиеш. Ә хатын-кыз бер-ике көн генә булса да өйдә тормый икән, өйнең яме калмый. Ни генә дисәләр дә, гаилә җылысын без саклыйбыз.

Блиц-сораштыру

– Авыр чакта иң зур терәгегез кем?
– Якыннарым. Ләкин беренче урында җан дустым – әбием.
– Сезне чыгырдан чыгара торган күренеш?
– Үз эшеңне начар башкару.
– Бүген теләсә кем чыгып җырлый аламы?
– Ала. Теләге һәм акчасы була икән, җырлый, әмма эстрадада озакка кала алмый.
– Татар эстрадасында иң еш очрый торган хата?
– Тиз арада үзләрен «йолдыз»га саный башлыйлар да тиз генә «сүнәләр».
– Иң шәп ял?
– Авылда, урманда.
– Тәртип ул – ...
– ...режим.
– Гөлназ Сәфәрова – брендмы?
– Әйе.

:: Ә хатын-кызның бәхете нәрсәдә?

– Аның гомуми формуласы юктыр инде. Кем өчендер ул – бер-бер артлы биш бала табып, пешеренеп, шул турыда блог алып бару. Кемнеңдер гаиләсе юк, үз бизнесы бар. Ни өчен ул бәхетсез булырга тиеш? Яраткан эше, үз көче белән ирешкән дәрәҗәсе бар икән, ул да бәхетле. Өченче тапкыр кияүгә чыккан хатын-кызны бәхетсез диләр. Нигә? Ул да бит үз бәхетен тапкан!

Ә минем өчен бәхет ул – гаиләм, яраткан эшем һәм якыннарымның янымда булуы.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Җырлар башка булса да, шартлар үзгәрмәде: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

«Ә нигә бикләргә? Урлар малым юк, үзебезне күтәреп алып чыгып китмәсләр», – дип көлде Гарифҗан абый. Ә капка бикләмәүнең үзенә күрә бер сәбәбе бар. Аның йорты автовокзал янында иде. Элек бит юллар начар, автобуслар бик сирәк йөргән. Кайчак автобуска өлгермәүчеләр дә булган, бигрәк тә авыл кешеләре. Урамда калган кеше кая барсын? Бигрәк тә кышкы, көзге салкын көннәрдә. Шундый кичләрнең берсендә Гарифҗан абыйларның ишеген шакыйлар. Ачса, яшь бала күтәргән ир белән хатын басып тора, ир кыяр-кыймас кына сүз башлый: «Абый, инде унбишенче йортка җиттек, капка ачучы юк. Баланы Казанга бүлнискә алып бара идек, автобуска соңга калдык. Мунчагызда булса да кунып чыгып булмас микән?» – ди. «Өй барында нинди мунча ул...» Шулай сөйләнә-сөйләнә, Гарифҗан абый тегеләрне өйгә алып керә. Хатыны Асия апа аш җылытып, нинди нигъмәт бар, шуны өстәлгә куеп, ашатып-эчереп йокларга яткыра боларны.

Җитәкчеләр арасында бүген мондый кешеләр күп микән, гомумән, бар микән әле дип уйлап куйдым. Ни дисәң дә, аның башкарма комитет рәисе урынбасары булып эшләгән чагы бит бу.

Икенче мизгел

Атеизмның гомере бетеп, диннең кыяр-кыймас кына баш калкыткан чагы. Шул елларда район мәктәпләрендә гарәп теле һәм дин нигезләре буенча сабак бирә башлыйлар. Мондый дәресләр программада юк һәм була да алмый иде әле, шуңа күрә өстә дә, аста да шактый ук тавыш куба. Укытучылар, мәктәп директорлары: «Гарифҗан абый, безне мәктәптән кудыртасың, эшсез калдырасың бит», – дип зар елар дәрәҗәгә җиткәләр. Районның мәгариф бүлеге һәм министрлык: «Сез нәрсә кыланасыз анда, ник закон бозасыз?» – дип бармак яный. «Сезгә Гарифҗан абый белән Җәлил хәзрәт Фазлыев керә инде. Шул чакта Гарифҗан абый: «Килер бер көн, безне иң олы, зур кешеләр дип искә алырсыз әле», – ди.

Әлбәттә, шау-шу алай тиз генә тынмый әле, хәтта прокуратурага хәтле барып җитә. Ул чакта республика прокуроры Кафил Әмиров була. Гарифҗан абый белән Җәлил хәзрәт үзләре керәләр янына, барысын да тыныч кына аңлаталар. Һәм прокурор аларга: «Барыгыз, тыныч кына эшләгез», – ди.

Бүген әлеге вакыйганы, бәлки, искә алучы да юктыр. Ә дин гыйлемен укыту исә шулай тиеш дип кабул ителә.

Өченче мизгел

Арбор авылы егете Гарифҗан Чепья авылында урта мәктәпне тәмамлый. Гел «бишле»гә генә укый ул. Инде соңгы имтиханнарны тапшырып, аттестат алу вакыты җиткәч, мәктәп директоры моңа: «Энем, урыс теленнән иншаны монда тикшергәннән соң Казанга җибәрәсе, тәртибе шундый. Синең иншаң «бишле» куярлык, әлбәттә, әмма татар баласына «бишле» куеп булмый, тәртип шундый. Әгәр сиңа алтын медаль урынына көмешне бирсәк, үпкәләмәссең микән?» – ди. «Мин медаль алу өчен түгел, белем алу өчен укыдым, үзегезгә карагыз!» – ди егет. Директорга, әлбәттә, үзенә түгел, ә Казанга карарга туры килә. Шулай итеп, Гарифҗанның өлгергәнлек аттестатына бердәнбер «дүртле» кереп оялый.

Мәктәп темасын кузгаткач, Гарифҗан абый сөйләгән тагын бер вакыйга турында языйм әле. Район, төбәк тарихын өйрәнгәндә ул бер гыйбрәткә тап була. Бу Арбор авылы кешесе Мөхәммәткамал Мөзаффаров исеме белән бәйле. Байда хезмәтче булган шушы фәкыйрь егет, эшләгән акчасын җыеп бара да, нибары сигез гаилә яшәгән Малмыжда татар мәктәбе ача. Шуннан Малмыжда татарлар ишәя башлый. Байда хезмәт иткән ярлы егеткә мәктәп ачу нигә кирәк булгандыр, шәхсән үзем моңа аңлату таба алмадым. Ә Гарифҗан абый: «Тарихыбыз гаҗәп бай, әмма таркау хәлдә. Аны өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле», – дип кенә куйды.

Дүртенче мизгел

Коммунистлар партиясе яшәүдән туктап, райком урынына район хакимиятләре оештырылган чак. Балтач районы хакимиятен шактый еллар Марат Әхмәтов җитәкләде.

Бер көнне социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча үзенең урынбасары булып эшләгән Гарифҗан абыйны кабинетына чакыра бу. Кулында – кайсыдыр районныңмы, шәһәрнеңме энциклопедиясе. «Ә нигә бездә мондый китап юк? Әйдә, галимнәрдән бер иҗат төркеме оештырыйк та эшли башлыйк әле!» – ди. Галимнәрне туплыйлар. Район тарихы буенча эзләнүләр башлана. Тик алар Гарифҗан абый көткән нәтиҗәне бирми.

Уйлашалар, киңәшәләр дә, зур гыйльми хезмәтне оештыру, башкару Гарифҗан абыйга тапшырыла. Татарстанның гына түгел, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Киров өлкәсе архивларында да утыра ул. Балтач заманында хәзерге Киров өлкәсе, элекке Вятка губерниясенә кергән була. Халыктан да бик күп мәгълүматлар җыя Гарифҗан абый. Нәтиҗәдә дәлилләнгән вакыйгаларны, язмышларны үзенә туплаган «Балтач энциклопедиясе» дөнья күрә. Бу – аның беренче китабы. Бүген, шигырь җыентыкларын да кертеп, 21 китабы бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Инде егерме икенчесен – Салавыч авылы тарихы турында яза башлаган.

«Шигърияткә вакыт калмый», – дип зарлангандай итә дә, киләчәк буыннарга тарихны калдыра алуы белән горурлана. Сиксән яшьтә бик үк дәртләнеп язып булмавын яшерми ул, тик дөньядан бурычлы булып китәсе килми, ди. Күзләрендә иҗат ялкыны бар әле, хушлашырга ашыкма, Гарифҗан абый.

Бишенче мизгел

Элек язучылар язгы-көзге кыр эшләре вакытында районнарга чыгалар иде. Балтач җитәкчелеге, Гарифҗан абый әйтмешли, «исемле», өлкән язучыларны чакыра торган булган. Һәм аларның килүе халык өчен зур бәйрәмгә әйләнгән. Аларны, гадәттә, Гарифҗан абый озатып йөргән.

«Бер елны Габдрахман Минский да килгән иде. Мин аның итагатьле, шактый ук шаян сүзле, бик зыялы булуына шаккаттым», – дип сөйләде Гарифҗан абый. Өч көн буе гәпләшеп йөргәннәр болар. Китәр алдыннан Габдрахман ага: «Үзең дә язасың бит, әйеме?» – дип куйган.

– Язгалыйм.

– Аларны теркәп барасыңмы соң?

– Дәфтәргә язып барам.

– Кая, миңа бирел җибәр әле. Иркенләп укып чыгыйм, кире кайтарырмын.

Габдрахман ага Казанга кайткач укып чыккан дәфтәрне Хәсән Туфанга биргән. Һәм бер көнне Хәсән ага Гарифҗан абыйга үзе шалтыраткан, «Казанга килсәң, миңа кереп чык әле!» – дигән. Бара бу Казанга, Хәсән ага янына керә. «Йөзе йончыган, алҗыган кебек күренде. Яшел япма бөркәнеп диванда ятып тора иде. Әмма минем белән әллә ничә сәгать буе сөйләшеп утырды», – дип искә ала Гарифҗан абый. Олуг шагыйребез матур сүзләр сөйләп тормаган. Һәр шигырь турысына үз фикерләрен язган. «Мондый шигырьләрне фәлән дә яза ала», – дип тә куйган. «Фәлән» дигәне шигърият тирәсендә әйләнеп йөрүчеләрнең берсе инде, мәгълүм сәбәп аркасында исемен әйтмик, урыны оҗмахта булсын. Хәсән Туфан кулы кергән дәфтәр әле дә саклана.

1985 елда Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Килегез, дусларым!» дигән беренче шигырьләр җыентыгы чыга, аңа кереш сүзне Хәсән Туфан үзе яза. Күп тә үтми, Гарифҗан абыйга Рөстәм Яхин шалтырата һәм Казанга, фатирына чакыра. Баксаң, ул Гарифҗан абыйның «Керим әле урманнарга» дигән шигырен көйгә салган икән. Шигырьне исә аңа әлеге дә баягы Габдрахман Минский тапшырган. Килеп керә егетебез композитор фатирына. Рөстәм Яхин шул ук йортта яшәүче Хәйдәр Бигичевны да дәшкән. Ул уйный, Хәйдәр җырлый, ә Гарифҗан абый һушы китеп өнсез кала. «Хәйдәр җилкәмә кулын куйгач кына аңыма килдем», – дип искә ала ул. Рөстәм Яхин исә: «Гарифҗан энем, җырның көе шигырьнең үзендә була ул, композитор аны эзләп табып җайга гына сала», – ди. Бөегебезнең бу сүзләрен гомергә онытмый Гарифҗан абый.

Шәхсән үзем әлеге шигырьгә башка көй, бу көйгә башка шигырь язып булмый дигән фикердә. Шулай да телевидениегә язылыр алдыннан шигырьне бераз үзгәртәләр. Художество советы әгъзаларының берсе: «Кара» дигән сүзләр артык күп, алай ярамый», – ди. Шулай итеп, һәр куплеты «керим әле урманнарга, урманнар карасына...» дип башланган җыр хәзер «Керим әле урманнарга, урманнар арасына...» дип җырлана. Ә Гарифҗан абый: «Урман арасына керү ничек була икән соң ул?» – дип аптырый.

Менә без Гарифҗан Садыйк улы Мөхәммәтшинның тормыш юлын бераз «нечкәләп» алдык. Тишек бишмәт белән авылдан чыгып китеп, үз көче, үз таланты белән үз язмышын ясаган кеше ул. Хәер, чын талантка арттан этү кирәк тә түгел. Талант һәрвакыт үзенә юл таба. Исән бул, Гарифҗан абый, эшлисе эшләрең, ай-һай, күп әле.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ҖЫРЛАП ЯШӘРГӘ!

Татарстандагы иң өлкән бабай бүген Казанда гомер кичерә. Бөек Ватан сугышы ветераны **Шәфыйк бабай Мөстәкыймов** 104 яшен тутырган. Гомере буе ашказанындагы җәрәхәт борчыса да, фронтка да алына, берничә операцияне дә уңышлы кичерә. Шәфыйк бабай әйтмешли, озак яшәү сере Аллаһы Тәгалә биргән гомергә бәйле. Кызы Әлфия ханым исә әтисенең озак яшәвен аның гел хәрәкәттә булуыннан күрә. 85–90 яшьтә дә күпме кирәк чапкан ул, үзе дә әлеге чор иң рәхәте иде, ди. Гомерлек юлдашы – җыр белән моң да ярдәм иткән, күрәсең. Катлаулы операциядән соң да җырлап ятарга көч тапкан ул һәм ике-өч көн дигәндә аякка да баскан. **Җырны йөрәк аша үткәрергә кирәк дигән фикердә бабакай. Шулай булганда, яшәү дә җиңелрәк.** Уен-көлкесез дә тормыш бармый, ничә яшьтә генә булсаң да, тормышны яратырга кирәк, ди ул.

КИЧКЕ АЛТЫДАН СОҢ АШАМАСКА!

Апас районының Олы Бакырчы авылында йөзьяшәрләр икәү. Без исә быел гына 100 яшен тутырган **Мәсбия әби Шәфигуллина**ның хәлен белештек.

«Әниебез ике яшендә ятим калып, әби-бабасы тәрбиясендә үскән. Ходай язган гомер булгач, ятимлек тә, кырыс сугыш еллары да, авыр хезмәт тә сындырмаган үзен. Җиде бала тәрбияләп үстергән. Иң олысы быел 80 яшен тутырды», – дип сөйләде безгә килене Гөлфия апа. Аның да Шәфигуллиннар йортына килен булып төшкәненә 41 ел булган инде. «Әнинең зарланганын бер дә ишеткәнем булмады. Тормышны ничек бар – шулай кабул итте. Авырлыкларны, Ходайның сынавы бу, дип сабырлык белән үткәрә белде. Шатлыкны сабыйлар кебек кабул итә иде», – диде килене.

Шәфигуллиннар фаразлавынча, **озын гомернең сере – тормышны авыр кабул итмәүдә**. Әниләре шулай өйрәткән. Организмны «тыңларга» да киңәш иткән. **Төн белән бербөтен булып яшәргә, кичке алтыдан соң ашамаска тырышырга кирәк икән**. «Йоклар алдыннан ашау организмга ял итәргә мөмкинлек бирми», – ди Мәсбия әби.

Әбинең 16 оныгы, 21 оныкчыгы бар. «Балаларым – байлыгым, исән-сау булсыннар дип, көн дә дога кылам», – ди ул.

АРТЫК СӨЕНМӘ ДӘ, КАЙГЫРМА ДА!

Мамадыш районының Түбән Тәкәнеш авылында гомер итүче 105 яшьлек **Өммениса Һадиева**ның әнисе дә 100 яшен тутырган булган. Хикмәт нәселдә генә түгелдер, Өммениса әби үзе дә: «**Озак яшәвемнең сере – кайгыга артык кайгырмауда, шатлыкка артык сөенмәүдә**. Кайгырып, бер нәрсә дә барып чыкмый. Үзеңчә матур итеп яшәргә кирәк», – ди. Гомере буе, нинди генә хәбәр ишетсә дә, тыныч күңел белән каршы алып, тыныч кына озатып җибәргән. Сәламәт булуының тагын бер сере – чишмә суы. Өенә су керттермәгән, гел чишмәдән ташыган. Бар белгән даруы – аспирин, хастаханәгә дә беренче тапкыр 100 яше тулганда гына мөрәҗәгать иткән.

Әбекәй илдәге сәясәттән яхшы хәбәрдар икән. Газета да укый, телевизор да карый. Быел менә сайлауда да катнашкан. Сәламәтлеге яхшы булмагач, өенә килгәннәр, билгеле.

«Җитди булып гомер итү авыр ул, балам»

Азнакайда гомер итүче **Хәдичә Шәйдуллина**га – 101 яшь. «ТНВ» телеканалы алып баручысы Ләйсәнә Садретдинованың яраткан апасы ул. Әбекәй бик зиһенле, әле дә укудан туктамый икән. Чын оптимист! «Җитди булып гомер итү авыр ул, балам. **Синең һәрвакыт елмаерга көчең булырга тиеш**». Бергә басып фотога төшкән чакта елмаймагач, Ләйсәнә ханымга шулай дигән Хәдичә әби. 95 яшенә кадәр үзе генә яшәгән. Кайчан гына сорасаң да: «Хәлем яхшы, тик бер көнгә картайдым шул», – дип җавап кайтара икән.

«СЕЗ БИТ ДӨНЬЯ КУАСЫЗ, АШЫКМАГЫЗ ЛА!»

101 яшьлек **Бибинур әби Хәснуллина** гомере буе балаларга аң-белем өләшкән. «Без яшь чакта укытып кына утырмадык, мәктәп җылы булсын дип, утынын да ярдык, башка эшен дә эшләдек. 30 чакрым ераклыктагы мәктәпкә җәяү барып йөргән чакларым да булды», – ди ул. Бүген улы янында Казанда яши. «Аягымны имгәттем, шуңа гына инде!» – ди үзе бу хакта. 101 яшькә җитүенең серен сорагач: «И балам, нинди сере булсын инде аның?! Булмышыбыз шундый, Аллаһы Тәгалә биргән гомерне яшибез. Аннары, без бит сезнең кебек химия ашап үсмәдек. Бар белгәнебез кычыткан, какы булды. Усә төшкәч, бәрәңге янында ипекәй булса, әй сөенә идек! Менә син шулай ипекәйгә сөенәсеңме соң?» Сөйләшкән арада берничә тапкыр сүгеп тә алды: «Ашыгасыз сез, ашыгасыз. Дөнья куасыз. Үзегез тизләтеп бетердегез тормышны! Вакыт юк, имеш. **Ашыкмагыз ла! Безнең кабаланган булмады, белмим, ничек җитешкәнбездер...**» Гомере буе укытучы булып эшләү нәтиҗәсе микән – Бибинур әби кулыннан китабын төшерми. «Телевизорны ачып, «Яңалыклар», «Башваткыч», «Туган җир» тапшыруларын карыйм да сүндереп куям. Калганына вакытым юк минем. Укый алганда укып каласым бар», – ди. Дөньядагы начар хәлләрне азрак тыңларга куша әбекәй: «Тормышыбыз бөтен бит. Татарстан үсә, камилләшә. Аеруча юлларга сөенәм, гел төзекләндереп торалар. Безнең вакытта алай булмады бит. Ә сез булганыннан да канәгать түгел».

«Озын гомер сере – кешегә начарлык теләмәү»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әбине улы Расих белән килене Рәсимә тәрбияли. Әби бу көннәрдә авырып тору сәбәпле, без улы белән сөйләштек.

– Безнең әни – тормышның ачысын да, төчесен дә күргән кеше. Хәзер уйлап-уйлап куям да, йөрәккәе ничек чыдады икән, дим, – ди улы Расих.

1941 елда ире Сәет сугышка киткәндә ул дүрт бала белән кала. Балаларын ач итмәс өчен, нинди эшкә кушсалар, шуны башкара. Ире сугыштан исән-сау кайта. Аннан соң тагын өч бала туа. Бүген бишесе генә исән. 1948 елда бер кызлары 16 яшендә суга батып үлә, 1953 елда уллары 14 яшендә фаҗигале төстә вафат була. «Әти белән әни шулкадәр сабыр булганнар инде. Хәсрәтләрен безгә күрсәтмиләр иде. Ана йөрәге өчен бала хәсрәтен күрүдән дә авыры юк бит! – ди Расих абый һәм өстәп куя: – Гомеренең озын булуы да сабырлыктандыр, мөгаен».

Хәер, аларның нәселе озын гомерле. Бертуганнары да озак яшәгән. Апасы 96 яшендә үлгән. Зәрига әбинең үз балаларының да иң олысына – 87, иң кечесенә быел 65 яшь тулган.

– Әнинең яшәү рәвеше дә башка иде аның. Әле дә хәтерлим: ул беркайчан да күп ашамады. Табын янынннан гел туяр-туймас кына китәр иде. Сыер итен бик сирәк кенә ашап куяр иде. Күбрәк тавык итен яратты. Камыр ризыкларын да үз итә. Әле дә өчпочмаклар пешереп ашатабыз. Әни бар нәрсәне рәхмәт әйтеп ашый, әмма чама белә. Балачакта аның үзенә дигән өлешне миңа бирүе исемдә калган. Шөкер, кайчандыр әнием мине үзе ашыйсы ризыгын биреп үстерсә, мин аңа рәхмәтемне кайтара алдым дип уйлыйм. 43 ел бергә яшибез. Әниебезне кадерләп торырга тырышабыз, – ди Расих абый. – Үзе дә безне күбрәк ярата, ахры. Калган туганнарым да үзләренә алып китмәкче була, кунакка булса да кил, дип чакыралар. Әмма әни бармый. Бездә генә тора. Димәк, начар яшәмибез. Мин хатыныма да рәхмәтле. Рәсимә беркайчан да авыр сүз әйтмәде, әнине үз анасыдай якын итеп тәрбияли. Әгәр якты йөз, яхшы сүз, тынычлык булмаса, әни дә бездә тормас иде. Олы кешегә әллә ни күп кирәкми – җылы сүзең җитә.

Зәрига әби авыр тормыш кичерсә дә, бирешмәгән. Патша заманында ук туып, Беренче Бөтендөнья һәм Бөек Ватан сугышы чорларын кичергән. Өч ел мәдрәсәдә укып, гомер буе колхозда эшләгән. Ире вафат булгач, бәетләр иҗат итә башлаган.

«Яшәү рәхәт, тик картайдык кына», – дип әйтә икән. Бу көннәрдә авырып торгач: «Бигрәк озак яшәлде. Йөздән узгач, авыррак икән», – дип тә куйган...

– Әни һәрвакыт намазда булды, – ди Расих Шәйдуллин. – «Йәсин» сүрәсен яттан сөйли. Догалар яшәтә аны. Аллаһы Тәгалә шуңа гомерен биргән. Аның күңеле сабый баланыкы кебек. Туганнарны якын итәргә, кеше белән сүзгә кермәскә, ачу сакламаска кушып үстерде. Әле дә шул киңәшләрне бирә.

Зәрига әби балаларына һәрвакыт хәрәкәттә булырга киңәш итә. Үзе дә 96 яшенә кадәр бакчада эшләгән. Озын гомернең тагын бер саллы кагыйдәсе – кешегә ачу сакламау, начарлык теләмәү.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

ТОРМЫШ, ИСӘНМЕ!

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ИҖАТЫНА ШТРИХЛАР

Шагыйрь нинди туфракта ярала? Аның тормышны ярату көче кайдан килә? Халык шагыйре Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА иҗатын укыганнан соң, үзеннән-үзе әнә шундый сорау туа. Шагыйрә гомеренең соңгы айларында да кулына каләм алырга һәм «Тормыш, исәнме!» дигән шигырен язарга көч таба бит. «Бөекләр эзеннән» сәхифәсенең унынчысын Саҗидә Сөләймановага һәм шушы әсәргә багышларга булдык. Аның өчен Саҗидә Сөләймановны шагыйрә буларак таныткан һәм соңгы көннәренәчә яшәгән Әлмәткә юл тоттык.

Әлмәт бакчалары

Юлдашларыбыз – шагыйрәнең улы, журналист Әнвәр Маликов, аның җәмәгате Асия ханым булды. Беренче тукталышыбыз – Әлмәт бакчалары. Төзелә генә башлаган шәһәр халкын туендырган җирдә Әнвәр абыйның истәлекләрен тыңлыйбыз:

– Әлмәтнең әле төзелә генә башлаган мәле. Юллар да салынмаган, кибетләр дә бик аз. Ипине дә чират белән генә алып була. Җиләк-җимеш, яшелчә ише нәрсәләрне табармын димә. Бу чорда теләгән кешегә алты сутый җир бүлеп бирелә иде. Әти-әни дә алды җир кишәрлеге. Менә шул алты сутый җир безне ашатты да инде. Анда бәрәңгесе дә булды, помидор-кыяры, җиләк-җимеше дә. Әни кыш чыгарлык кайнатмалар ясый, гомумән, мөмкин булганның барысын да эшли иде. Ә менә бәрәңгене кышка сакларга куярга кирәк. Шәһәр кырыенда баз казучылар да булды. Әтием кем беләндер сөйләшеп, кышка дигән бәрәңгене шул базларның берсенә куя иде.

Саҗидә апа яшәешенең бер чите ачылып, аның уңган хуҗабикә булуын гөманлыйк та, алга таба кузгалыйк.

Туган якны өйрәнү музее

Биредә Саҗидә Сөләймановның эш урыны белән танышып була. Анда секретер, өстәл, үзе теккән күлмәкләр, тегү машинасы тора. Әнвәр абый, ул елларда, теге яки бу эшнең җаен беләсеңме дигән сорау тумый, эшләргә кирәк, өйрәнергә кирәк, дип яшәделәр, дип искә ала:

– Әнием күлмәкләрен үзе текте, безне дә киендерде. Матур киенергә бик ярата иде.

«Москва» дигән машинкасы да биредә саклана. Татар хәрефләрен кустар мастердан ясатып, үзебез куйдырдык. Кыекмыек шрифт булса да, татар хәрефләре дип шатлана иде әни. Ләкин татар хәрефләре куйдыргач, кайбер рус хәрефләре төшеп калды. Миңа да мәктәпкә кайбер эшләрне бастырып алырга кирәк була. Җитмәгән рус хәрефләрен кулдан язып куя идем.

Әлмәт Татар дәүләт драма театры

Ул безне үстерде, үсендерде. Әлмәт театрының өлкән артистларының берсе – Татарстанның халык артисты Луиза Солтанова безне әнә шулай каршы алды:

– 1964 елда драматург Сәет Кальметовның «Тамгалы йорт» әсәре буенча спектакль куелды. Аны без менә шушы бинада уйнадык. Ләкин ул вакытта бу бина тора-бара безнеке булыр дигән уй әле хыялда да юк иде. Спектакльне ике көн уйнадык. Репетицияләрнең берсендә Татарстанның халык артисты Ләлә апа Садыйкова: «Луиза, бүген сәгать унга шагыйрә Саҗидә апа Сөләйманова килә, ул сине бик күрергә тели», – диде. Мин 1963 елда Әлмәттә Язучылар оешмасы барлыкка килгәнен ишетеп кенә беләм, ләкин бер язучыны да күргәнем дә, аралашканым да юк. Коелып төштем. Нәрсә әйтергә, нәрсә сөйләргә дә белмим ләбаса. Нәкъ шушылай фойега чыгып утырдык. Бер ханым килеп керде. Ул бөтенләй мин күзаллаганча түгел: ап-ак йөзле, аксыл чәчле, зәңгәр күзле. Каушаганымны сизгәндер дип уйлыйм, ипле генә, җиңел генә итеп сөйләшә башлады. Тора-бара аның язучы булуы да онытылды. Рәхәт итеп аралаша башладык. Ничек эшли башлаганымны, нинди рольләр башкарганымны да белеште. Мин – 1962 елда эшкә килгән бала. Ул вакытта кыска гына, вак кына рольләр булды. Бусы инде олырак, героиня роле иде. Менә шулай 19 яшемдә мин Саҗидә Сөләйманова белән беренче тапкыр сөйләштем һәм без шул аралашудан гомерлек дусларга әйләнеп калдык.

Сәҗидә апа Дамирә Кузаева, Роза Салихова, Камил Вәлиев, мин – безнең белән якыннан аралашты. Еш кына фатирына кунакка чакыра иде. Шундый аралашуларның берсендә ул театрга килгән яшь актерларга рецензия язып карарга тәкъдим итте. Тагын аптырап калдым. Ничек инде, дим, мин бит яза белмим! Беркем дә яза белеп тумый, акрынлап өйрәнәсең, ди. Икенче көнне язган булып килдем. Укыды, азрак кына төзәтергә кушты, фикерләр өстәтте. Яңадан яздым, яңадан бардым. Өч мәртәбә төзәтеп язганнан соң «Театрга яшьләр килә» дигән рецензия «Ватаным Татарстан» газетасында басылып та чыкты.

Хәзер уйлыйм: ничек безгә вакыт тапкан, безне «үстергән», ничек аралашасы килгән икән? Өенә чакырып, җылы итеп каршы алып, чәй эчереп... Әле бит гаиләгә вакыт табасы, кырыкмаса кырык эшкә өзерләнәсе. Ул вакытта Әлмәт радиосында журналист та, диктор булып та эшли иде бит. Диктор дигәннән, бервакыт магнитофоннан тавышын тыңладым да таң калдым. Үзара сөйләшкәндә бер төрле, радиода исә бөтенләй икенче төрле тавыш!

Луиза апа иң кадерле мизгелләрне искә алганнан соң, Саҗидә Сөләймановны озату кичәсен дә хәтерендә яңартты. Без аның бер күзәтүен аерып бирергә булдык. Ир белән хатын арасындагы кайгыртучанлыкка, мәхәббәткә мисал ул:

– Театрдан җыелышып бардык, Әдип абый язу эшләре белән йөреп кайтырга дип чыгып китте. Без мәрхүмәне саклап калдык. Саҗидә апаның күзләрен йомдырып, өстенә биш тиен акча куйдылар. Татарда шундый гадәт бар... Берзаман Әдип абый кайтып керде һәм Саҗидә апа янына килеп, тынгысызлана башлады:

– Биш тиен бигрәк авыр бит ул, зинһар, өч тиен акча табыгыз... – дип үтенде. Тәңкәләрне алмаштыргач кына Әдип абый тынычлангандай булды. Бу да бит кайгырту, бу да ярату, хөрмәт билгесе...

Саҗидә апа гомер буе тыныч, сабыр булды. Тәнкыйтьне дә сак кына, итагатьле итеп әйтә белде.

> Саҗидә Сөләймановага Тукай премиясе бирелми калды. Әлбәттә, бер карасаң, фаҗига дип әйтеп буладыр бу күренешне. Ләкин ул халык күңелен шулкадәр яулап алган иде инде, дәүләт бүләкләре, өстәгеләрнең тануы ничектер икенчел булып калды. Аның иртә китүе фаҗига булды, бүләк алмавы түгел.

Татарстанның атказанган артисты Наилә Нәҗипова исә шагыйрәнең тарту көченең серләрен барлады:

– Ул тыйнак, ул сабыр, ул чын. Шуңа да аның шигырьләре актуаль, әйтерсең лә бүген язылган. Аларда шулкадәр күп фәлсәфә, алар шундый тирән. Совет чорында иҗат итүнең үзенең үзенчәлекләре булгандыр. Соцреализм шигырьләрен алыйк: анда герой бар, шатлык... Ә Саҗидә Сөләйманованың шигырьләрендә – «дөнья ул оҗмах түгел, ул каршылыклы, аның бик куркыныч кануннары бар. Шул кануннар буенча яшәп тә, кешелегеңне югалтма, дөньяны акла» дигән фикер ята. Аның иҗатында да, тормышында да кешеләрне яратуы күренә. «Иҗат кешесе нинди булырга тиеш?» – дип сорасагыз, «Саҗидә Сөләйманова кебек», – дияр идем. Безгә бүген шәхесләр кирәк. Саҗидә Сөләйманова шәхес булган ул. Кешеләрне, халкын, тормышны яраткан шәхес.

> Шигърияттә беренче, икенче, өченче урыннар булмый. Чын шигъриятнең еллар аша калкып чыга торган көче була. Саҗидә Сөләйманова шундый. Шуңа яратты да аны халык. Күпме кешене шигырь укырга өйрәтте, күпме кешене шигърияткә борды бит ул.

Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге

Язучы Рәфкать Шаһиев белән ул вакыттагы әдәбият һәм бүгенгесе арасындагы аермага тукталдык:

– Бүген әдәбиятны халыкка җиткерергә, пропагандаларга кирәк, дип бик еш әйтәләр. Тик бу бүген – сүздә генә. Ул вакытта исә әдәбиятны халыкка җиткерү гамәл булган. Язучылар халык яныннан кайтып кермәгән. Бу җәһәттән Саҗидә апа – уникаль шәхес.

Әдәбиятны ир-атныкына, хатын-кызныкына бүлеп карау да бар. Саҗидә апаның иҗатын алай бүлеп булмый. Аның елап укый торган иҗат түгел. Көчле гражданлык позициясендә язылган, елый башлаган кешенең дә күзен сөртеп ала, рух бирә торган иҗат. Шуңа да үлемсездер ул.

> Саҗидә апа үзе исән чагында да, хәзер дә популяр. Әйе, Тукай премиясенә тәкъдим ителгән һәм алынмый калган. Һәм ул чорда ир-ат буларак юл куймаган кешеләр бүген дә исән һәм алар бүген аның иҗатын күкләргә чөеп мактый.

Юлыбыз китапханәгә дә, шагыйрә яшәгән йортларга да илтте. Соңгысында – Ленин урамындагы 24 нче йортта шагыйрә соңгы көннәрен үткәргән. Бу йорттагы фатирга Әнвәр абый 1984 елдан бирле аяк басмаган булган. Хәзер инде әлеге фатирда бөтенләй башка кешеләр яши. Әнвәр абый батырчылык итеп, әлеге фатирга яңадан керде. Андагы рух, хуҗабикә турында видеодан карап белергә була.

Без исә Әнвәр абыйдан шәхес баласы булу җаваплылыгы турында да сорамый булдыра алмадык:

– Язучы баласы булу – зур җаваплылык. Бер язучы Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияне тапшыру тантанасыннан соң, шәхес баласы булу рәхәтме, дип сорады. Мин җавап бирә алмадым. Бу сорау бик озак борчыды. Әле менә бу кичәдә дә миңа игътибар күп булды. Лаекмы соң мин ул игътибарга? Чөнки бит ул әниемнең – Саҗидә Сөләйманованың бәйрәме. Әлбәттә, аның исемен мәңгеләштерү, иҗатын халыкка җиткерү буенча җәмәгатем Асия белән даими эшлибез. Монда әтиемнең роле дә зур булгандыр. Ул әниемнең мирасын күтәрү өчен бик зур көч куйды. Аннан ул эш миңа калды...

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

«БӨЕКЛӘР ЭЗЕННӘН» СӘХИФӘСЕНЕҢ ВИДЕОСЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

КЕШЕ КИТӘ, КӨРӘШ ЭЗЕ КАЛА

Көрәш җәмәгатьчелеге Равил Хәйруллинны соңгы юлга озатты. Татарстанның көрәш федерациясе башкарма директоры белән хушлашырга Казандагы 7 нче хастаханә янына халык күп җыелды. Җылы сүзләр әйттеләр, хатирәләр яңарттылар, дога кылдылар. Исәннәргә алга таба да көрәшергә туры киләчәк: киләмдә батыр калу гына түгел, мәгълүм авыруны җиңү өчен дә.

Мәрхүм белән хушлашу мәрасимен Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, көрәш федерациясе җитәкчесе Марат Әхмәтов алып барды. «Аның киткәненә әле дә ышанып булмый. Портфелен күтәреп килеп керер дә көрәш турында фикерләрен җиткерә башлар кебек. Бу кадәр кешенең җыелуы тагын бер тапкыр дустыбызның никадәр якты кеше булуы турында сөйли», – диде ул Равил Хәйруллин турында. Татарстанның Муниципаль берәмлекләре ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин дустының тормышта зур сынаулар аша узып, күтәрелүе турында искә алды.

Свердлау өлкәсендә туа ул. Әнисе бу якларга комсомол тәзелешенә барып эләгә. Малайга авырлыкларны кечкенәдән үк татырга туры килә. Әтисе вафат булгач, әнисе аны туган ягына – Корсабаш авылына алып кайта. Кечкенә Равил бабасы белән әбисе тәрбиясендә үсә. Көрәш мәйданына да бабасы алып чыгалар. Спорт белән ныклап торып Чистайдагы совхоз-техникумда шөгыльләнә башлый. Бәхетенә, биредә данлыклы тренер Мәгаз Сәхәбетдинов кулы астына эләгә. ТАССР чемпионатында көмеш медаль яулый, 1972 елда яшьләр арасында Россия чемпионы булып танылa. Армиягә барып кайткач, Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. Биредә янә Мәгаз Сәхәбетдинов җитәкчелегендә шөгыльләнә. Бу юлы инде уңышлар да арта, Равил Хәйруллин грек-рим көрәше буенча СССРның спорт остасы исеменә лаек була. Институтны тәмамлап, авыл хуҗалыгында эшли башлагач та, көрәштән ерак китми ул. Питрәчтә егетләрне туплый, ә Балык Бистәсендә башлык булып эшләгәндә, бу район егетләре республикада иң көчле командалардан саналды, зур ярышларда беренче урынны алды.

Моннан унбер ел элек Равил Хәйруллин Татарстанның көрәш федерациясе башкарма директоры итеп билгеләнде. Кирәк чакта түрәләр белән алар телендә, көрәшчеләр белән егетләрчә сөйләшә белде. Татар батырлары тәҗрибә тупласын, башкалар белән бил алышып осталыгын арттырсын, дөнья күрсен дип мөмкинлек булган саен сәфәр чыгарга тырышты. Көрәш дөньясында үзен иң шәп батыр, иң яхшы тренер, иң гадел хөкемдар дип санаучылар да җитәрлек. Башкарма директор җиде кат үлчәп, бер мәртәбә кисәргә тырышты. Замана коточкыч тизлек белән үзгәргән чорда милли спорт төрен ничек тә саклап калу өчен җан атты. Бүгенге батырлар бу исемгә лаек булсын, җиңүдән башлары әйләнмәсен, элеккегеләре исә онытылмасын дип хезмәт куйды.

«Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган, герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә узучы турнирга аерым мөнәсәбәттә булуын беркайчан да яшермәде Равил Хәйруллин. Бу бәйге иң мәртәбәле ярыш булган өчен генә түгел. Муса Җәлилнең геройлыгы турында һәрвакыт сокланып сөйләде ул. Алманиягә барып, аның эзләреннән йөргәнен еш искә ала иде.

Кыскасы, үзе дә эшләде, башкаларны да тик тотмады. Әле мәрхүмне озатканда танылган хөкемдар Әухәт Мөхәммәдиев сөйләп торды: «Узган атнада Сабада буласы турнир турында ахырга кадәр белешеп торды. Хәленең яхшырасына өметләнеп, эшкә чыгарга хыялланды. Ә шимбә көнне телефонын алмый башлады...»

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ХӘЙРУЛЛИН РАВИЛ ГАРИФУЛЛА УЛЫ

(01.02.1954 – 05.10.2021)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры, Балык Бистәсе районының элекке хакимият башлыгы Хәйруллин Равил Гарифулла улы 5 октябрь көнне 68 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Равил Хәйруллин 1954 елның 1 февралендә Свердловск өлкәсенең Краснотурьинск районы Волчанка бистәсендә дөньяга килә. 1973 елда Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген ТАССРның Саба районы «Победа» колхозында башлап җибәрә. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. Студент елларында грекрим көрәше буенча тренер булып эшли. 1975, 1977 һәм 1978 елларда спортның әлеге төре буенча ТАССР чемпионы исемен яулауга ирешә. 1976 елда авыл спортчылары арасында СССР чемпионаты призеры һәм СССРның спорт мастеры, 1977 елда авыл спортчылары арасында РСФСР чемпионы була.

Равил Гарифулла улы 1980–1994 елларда Арча районы хуҗалыкларында зоотехник, Азин исемендәге һәм «Корса» колхозлары рәисе вазыйфаларында хезмәт куйды. 1994 елда Питрәч районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе итеп билгеләнде.

1998 – 2006 елларда Равил Хәйруллин Балык Бистәсе районына җитәкчелек итте. Шушы еллар эчендә үзен югары квалификацияле, инициативалы, оста оештыручы, көч-энергиясе ташып торган булдыклы җитәкче буларак танытты. Авыр елларда ул районның социаль-икътисади үсешендәге уңай динамиканы саклап калуга ирешә. Авыл җирлегендә торак, социаль-мәдәни һәм җитештерү объектларын төзү, авылларны төзекләндерү мәсьәләләрен хәл кылуга үзеннән зур өлеш кертте.

2006 елда Равил Хәйруллин «Ак Барс» банкы ачык акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе киңәшчесе итеп билгеләнде. 2010 елның декабреннән Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры булып торды. Равил Гарифулла улының актив катнашында республикада спортның әлеге төрен үстерү программасы эшләнеп кабул ителде. Соңгы җиде елда Татарстан җыелма командасы Россиядә зурлар, шулай ук яшьләр арасында үткәрелгән барлык команда ярышларында җиңүгә ирешә. Аның җитәкчелегендә 32 спортчы көрәш буенча дөнья чемпионы булды.

Максатка ирешүдәге ныклыгы, оптимизм рухына ия булуы, кушылган эшкә бик зур җаваплылык хисе белән каравы югары дәрәҗәдәге дәүләт бүләкләре белән билгеләнде. Алар арасында – «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» һәм «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре, «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре», «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» мактаулы исемнәре. Милли көрәшне популярлаштыруга зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнде.

Равил Гарифулла улы Хәйруллинның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, М.Ш. Шәймиев,
Ф.Х. Мөхәммәтшин, А.В. Песошин,
Ә.Ә. Сәфәров, М.Г. Әхмәтов, М.А. Җәббаров,
В.А. Леонов, Ә.С. Гобәйдуллин,
И.Р. Метшин, И.Р. Тажетдинов

ДЕМИДОВ НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ

(08.04.1933 – 06.10.2021)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Элекке СССР эчке эшләр министры урынбасары, ТАССР эчке эшләр министры, эчке хезмәт генерал-лейтенанты Николай Иванович Демидов 6 октябрьдә 89 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Николай Демидов 1933 елның 8 апрелендә ТАССРның Лаеш районы Урта Девятово авылында туа. Хезмәт эшчәнлеген 1950 елда Лаеш районының Чирпы җидееллык мәктәбендә укытучы буларак башлап җибәрә.

1956 елда В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, ТАССРның Алабуга районы прокуроры ярдәмчесе вазыйфасына билгеләнә. 1958–1978 елларда партия эшендә: ВЛКСМның Алабуга район комитеты беренче секретаре, КПССның Алабуга район комитеты секретаре, КПССның Алабуга шәһәр комитеты секретаре, ТАССР хезмәт ияләре депутатларының Түбән Кама район советы башкарма комитеты рәисе, КПССның Татарстан өлкә комитеты пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире вазыйфаларында хезмәт куя.

Николай Демидов 1978 елда ТАССР эчке эшләр министры итеп билгеләнде. Ул, җинаятьчелеккә каршы аяусыз көрәшеп, республикада иминлекне һәм хокук тәртибен саклауга саллы өлеш кертте. Николай Иванович хокук саклау органнарын ышанычлы кадрлар белән тәэмин итү буенча киң колачлы эш башкарды.

1983 елда СССР Эчке эшләр министрлыгына – министр урынбасары – БХСС идарәсе җитәкчесе вазыйфасына күчерелде. Аның актив катнашында Мәскәүдә, Ростов-Дон, Краснодар крае, Урта Азиядә һәм кайбер башка төбәкләрдә күп кенә оешкан җинаятьчел төркемнәр фаш ителеп, юкка чыгарылды. Ике елдан соң Николай Демидовка барлык оператив хезмәтләргә кураторлык итү йөкләнде: ул СССР Эчке эшләр министрлыгының фәнни-техник советы башлыгы булды. 1986 елның май – июнь айларында Чернобыль һәлакәтенең аянычлы нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча СССР Эчке эшләр министрлыгының оператив штабына җитәкчелек итте.

Җинаятьчелеккә каршы көрәш өлкәсендә зур оештыру тәҗрибәсенә ия булуын исәпкә алып, Николай Демидов 1991 елда яңа оештырылган уку йортына – Бөтенроссия эчке эшләр органнарының квалификация күтәрү институтына җитәкче итеп куелды. 1994 елда эчке эшләр органнарының төп уку йорты һәм фәнни оешмасы – Россия Эчке эшләр министрлыгы академиясе җитәкчесе вазыйфасына билгеләнде. 1997 елда Россия табигать фәннәре академиясе академигы – хакыйкый әгъзасы итеп бертавыштан сайланды. Николай Иванович хокук саклау органнары өчен йөзләрчә профессионал, оперативник һәм җитәкче тәрбияләп, аларны олы тормышка озатты.

Николай Демидов VIII, IX һәм X чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланды. Лаеклы ялга чыккач, «Эчке эшләр министрлыгы – Чернобыль калканы» чернобыльчеләр берләшмәсенә җитәкчелек итте, яшь буынга белем-тәҗрибәсен тапшырып, актив иҗтимагый эшчәнлек алып барды.

Николай Ивановичның тормыш юлы бик зур ихтирам-хөрмәткә лаек. Ул кайда гына эшләмәсен, үзен югары дәрәҗәдәге профессионал, зирәк, үз эшенә тугры ватанпәрвәр шәхес буларак танытты.

Николай Демидовның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Хезмәт Кызыл Байрагы, Батырлык, «Почет билгесе», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре.

Николай Иванович Демидовның – илебезнең иминлеген тәэмин итүгә үзеннән бик зур өлеш керткән талантлы җитәкче һәм оештыручының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин,
А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, А.В.Хохорин, Р.В.Гыйльманов,
И.Р.Метшин, И.Ф.Зарипов

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, сигезенче, тугызынчы һәм унынчы чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты, элекке ТАССР эчке эшләр министры (1978 – 1983), СССР эчке эшләр министры урынбасары (1983 – 1991), эчке хезмәт генерал-лейтенанты

Николай Иванович ДЕМИДОВның

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спас муниципаль районы советы, башкарма комитеты, абыйсы

Николай Ивановичның

вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Демидов Алексей Ивановичның авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әтисе

ФРОЛОВ Владимир Федоровичның

вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты Экспертлар департаменты Икътисади анализ идарәсенең инвестиция проектлары секторы мөдире Фролов Павел Владимировичның авыр кайгысын уртаклаша.

Язучы фикере

НИ ӨЧЕН?

Бер дус бар минем. Аннан-моннан мәгълүмат җыя да шуны үзе күргән кебек итеп тәмләп сөйли. Кайчагында бераз шыттырып та җибәрә. Әмма тыңлавы рәхәт. Шуңа мин аның сүзен гадәттә тикшереп карыйм. Бу юлы да шулай килеп чыкты.

– Соңгы ике ел эчендә Кытай Америка йөз елда эшләгән күләмдә цемент җитештергән.

Мин ышанмыйм. Төрле чыганаклардан белешеп карыйм. Шулай. Сокланырга, тел шартлатырга кирәк бит инде.

– Ни пычагыма кирәк аларга шулхәтле цемент?

– Юллар төзү өчен. Тиз йөрешле юллар гына да анда ел саен 10 мең километр озынлыгында төзелә. Егерме ел элек анда мондый юллар бөтенләй булмаган, ә хәзер...

Шайтан алгыры! Тапкан бит горурланыр нәрсә, ә. Кытай, имеш. Юллар, имеш.

– Шул гынамы? Юлны аны бездә дә төзиләр... – димен дә асфальт ватылган урынга кергән машина кебек туктап калам. Соңгы тапкыр яхшы юллардан кайчан узганымны хәтерләргә тырышам. Искә төшми. Салават җырлаган җыр гына искә төшә: «Каторжан юлы, каторжан юлы...»

– Ә күперләр! – дип дәвам итә теге. – Бүген Кытайда өч йөз мең күпер бар. Шуларның меңнән артыгы бер километрдан озынрак.

– Һи, безнең Казанда да бар инде күперләр. Ә анда «бөке»гә эләккән машиналарның озынлыгы кайчагында ун километрдан да арта.

Ә теге дәвам итә:

– Аэропорт! Кытайның һәр кечкенә төбәгендә дә аэропорт ачачаклар. Бүген анда 400 аэропорт булса, бу сан якын елларда 2 меңгә җитәчәк.

Ел саен йөз булгач әйбәт инде, канишны. Тик сер бирәсе килми. Нәрсәдер әйтәсе килә. Әйтеп кенә булмый. Ә теге мәхлук мактануын белә:

– Тимер юллар. Бүген Кытай дөньяда иң зур тимер юл челтәренә ия. Югары тизлектәге юллар буенча ул Японияне һәм Европаны әллә никадәр артта калдырган. Ә Шанхай белән Пекин арасына җибәрелгән поезд Американың иң тиз йөрешле поездына караганда ике тапкыр кызуырак йөри.

– Ә торак! – дип күз ачырмый теге. – Ун еллар чамасы элек кеше башына 4 квадрат метр туры килсә, бүген бу сан – 32, Россиягә караганда да күбрәк. Үсү темпы исә бөтенләй тиңсез. Ә бәяләре!.. Пекинның гади кешесе еллык хезмәт хакына 10 квадрат метр торак мәйдан сатып алала. Бернинди ипотека кирәкми – хатының белән ике-өч ел эшлисең дә фатирлы буласың.

Соңгы сүзе бөтенләй нервыга тия. Нинди оятсызлык бу кытайларда, ә?! Ник шулай рәхимсез рәвештә көләләр безнең ипотекадан?! Нормальный Россия кешесе шикелле бер фатир өчен утыз ел түләрлек итеп эшләсәләр булмыймыни инде?! Нәрсә, аларда чиновниклар юк микәнни? Ул чиновникларның балалары, оныклары, туганнары, туганнан туганнары, дуслары, таныш-белешләре юк микәнни?! Аларга гына гел коммунизмда яшәргә димәгән ич!

Ә теге сөйли... Соңгы ун елда сәнәгать өлкәсендә... Соңгы ун елда фән өлкәсендә... Соңгы ун елда... Мин инде аны ишетмим. Ишетәсем дә килми. Ачудан шартлар чиккә җиткәнмен. Шартлыйсым килә. Кредит түләргә дип җыйган акчага ару гына итеп ашап шартлыйсым һәм бөтен Кытай өстенә чәчрисем килә... Ни өчен соң... Ни өчен...

Минем җан авазым тегенең дә аңына барып җитә бугай:

– Ә беләсеңме ни өчен? – дип елмая.

– Ни өчен?

– Соңгы ун елда коррупция өчен 10 мең чиновникны атканнар, ә 120 меңен төрмәгә утыртканнар.

Мин дәшмим. Ни дип әйтеп була. Шаяртадыр инде.

Марат КӘБИРОВ



Рәис Габдулла

1 октябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: үрнәк, бәйлек, Аксу, учар, яр, ияр, Урава, әмма, Лос, Әсрар, Кяро, Рус, еру, галифе, борчак, термос, туу, ахмак. **Вертикаль буенча:** бая, әгәр, Әкрам, сумо, «Ройс», Марс, Луиза, фрегат, кукуруз, ракета, кул, рух, Азалия, мум, Во, Руффо, Лас, сак.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерә аласыз.

1 Әби-патша Екатерина II Казанга кайчан килә?

А) 1801 ел;
Б) 1177 ел;
В) 1767 ел.

2 Казан федераль университетының фәнни китапханәсе кем исемен йөртә?

А) Н. Лобачевский;
Б) Л. Толстой;
В) С. Сәйдәшев.

3 «Бәк» сүзе нәрсәне аңлата?

А) төрки халыкларда ыруг, кабилә башлыкларының дәрәҗәле исеме-титулы;
Б) мыскыллап әйтә торган сүз;
В) хөкемдар.

4 «Авыл түгел, дустым, ил югалттык һәм дә хәтта чырай сытмадык. Барысына барып җиттек бугай һәм туктыйсы җирдә тукталдык». Бу шигырь юллары кемнеке?

А) Роберт Әхмәтҗанов;
Б) Зөлфәт;
В) Мөхәммәт Мәһдиев.

5 «Сөембикә» журналы 1913 елда кем җитәкчелегендә чыга башлый?

А) Сәгыйть Рәмиев;
Б) Сибгат Хәким;
В) Якуб Хәлили.

Җаваплар: 1) В; 2) А; 3) А; 4) Б; 5) В.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 346

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+